Принято
Педагогическим советом
Протокол №1 от 29.08.2025 г.
Введен в действие приказом
№67 от 29.08.2025 г.

Потапова Ирина Юрьевна

Подписано цифровой подписью: Потапова Ирина Юрьевна
DN: c=RU, st=Республика Татарстан (Татарстан), l=Казань, title=Заведующая, o=МУНИЦИПАЛЬНОЕ АВТОНОМНОЕ ДОШКОЛЬНОЕ ОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ "ДЕТСКИЙ САД №252 КОМБИНИРОВАННОГО ВИДА" КИРОВСКОГО РАЙОНА Г.КАЗАНИ, 1.2.643.100.3=120B303436373036333136353 6, 1.2.643.3.131.1.1=120C313635363034303733 353730, email=it-cbo@yandex.ru, givenName=Ирина Юрьевна, sn=Потапова, cn=Потапова Ирина Юрьевна
Дата: 2026.03.13 13:01:18 +03'00'

Казан шәһәре Киров районының «252 нче катнаш төрдәге балалар бакчасы» МАМБУ балаларга татар теле өйрәтүче тәрбиячесенең 2025-2026 нче уку елы өчен эш программасы

Мәктәпкәчә белем бирү Федераль дәүләт белем стандартын күздә тотып, укыту методик комплектларга нигезләнеп төзелде.

Әзерләде: Зиганшина Э.И.

ЭЧТӘЛЕК

Кереш сүз 4

1 НЧЕ МАКСАТЛАР БУЛЕГЕ 5

1.1. Аңлатма язуы 5

1.1.1. Программаның максаты һәм бурычлары 5

1.1.2. Программаны формалаштыру принциплары һәм ысуллары 6

Коммуникативлык принцибы балаларны татар телен аралашу ча¬расы буларак куллануга әзерли. Телне фән буларак түгел, ә аралашу чарасы буларак өйрәтә. 6

Тел өйрәтү, тәрбия һәм үстерү бурычларының бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә тормышка ашырылу принцибы. 6

Дәвамчанлык принцибы балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәптә эзлеклелекне күздә тота. 6

Белем бирү эшчәнлегенең мотивлашкан булу принцибы - бала материалны үзе өчен кызык булганда, үзенең шәхси ихтыяҗларына туры килгәндә генә кабул итә һәм фикерли башлавында. Тел өйрәтү процессында әкияти сюжетлар карау, кызыклы таныш геройлар (Акбай, Мияу) белән очрашу, уен элементларын куллану тел материалын өйрәнүнең мотивлашкан булуын тәэмин итә. Телне аралашуга, уен ситуацияләренә бәйләп өйрәнгәндә, балалар тел өйрәнүнең практик әһәмиятен тоялар, эмоциональ күтәренкелек туа һәм алар тел мате¬риалын бик теләп үзләштерәләр. 6

Индивидуальләштерү принцибы тел өйрәткәндә социаль шәхес сыйфатларын үстерүне күздә тота. Балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә ала. 6

Күрсәтмәлелек принцибы тел өйрәтүне, көндәлек тормыштагы һәртөрле эшчәнлеккә бәйле рәвештә, балаларның тирә-юньне танып белүендә төп чара булып торган уен аша үткәрә. 6

Интеграция принцибы - һәр сөйләм төренең үзенчәлеген исәпкә алу, тәрбияче сөйләмен техник чаралар ярдәмендә (аудио-, видеояз-мада) тыңлау (аудирование), тел үзәнчәлекләрен төрле күнегүләрдә бирү, балаларның диалогик сөйләмен үстерү.Программа үзләштерүдә көтелгән нәтиҗәләр 6

1.2. Программаны үзләштерүнең нәтиҗәләре 7

«Татарча сөйләшәбез» проекты буенча максат ориентирлары 7

Зурлар төркеме (5-6 яшь) “Уйный – уйный үсәбез” проекты 8

Мәктәпкә әзерлек төркеме (6-7 яшь) “Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар”проекты 9

«Туган телдә сөйләшәбез» проекты буенча максат ориентирлары 10

Беренче кече яшьтәгеләр төркеме (2-3 яшь) «Туган телдә сөйләшәбез» 10

Икенче кече яшьтәгеләр төркеме (3-4 яшь) «Туган телдә сөйләшәбез» 11

Уртанчылар төркеме (4-5 яшь) «Туган телдә сөйләшәбез» 12

Зурлар һәм мәктәпкә әзерлек төркеме (5 - 7яшь) «Туган телдә сөйләшәбез» 13

1.3. Программаны үзләштерүнең педагогик диагностикасы 15
2 НЧЕ ЭЧТӘЛЕК БҮЛЕГЕ 17
2.1. «Татарча сөйләшәбез» проекты 17
Уртанчылар төркеме (4-5 яшь) «Минем өем» проекты 17
УРТАНЧЫЛАР ТӨРКЕМЕ «МИНЕМ ӨЕМ» ПРОЕКТЫ БУЕНЧА ТЕМАТИК ПЛАН 18
Зурлар төркеме (5-6 яшь) «Уйный – уйный үсәбез» проекты 23
ЗУРЛАР ТӨРКЕМЕ 24
«УЙНЫЙ-УЙНЫЙ ҮСӘБЕЗ» ПРОЕКТЫ БУЕНЧА ТЕМАТИК ПЛАН 24
Мәктәпкә әзерлек төркеме (6-7 яшь) «Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар» проекты 29
МӘКТӘПКӘ ӘЗЕРЛЕК ТӨРКЕМЕ «БЕЗ ИНДЕ ХӘЗЕР ЗУРЛАР – МӘКТӘПКӘ ИЛТӘ ЮЛЛАР» ПРОЕКТЫ БУЕНЧА ТЕМАТИК ПЛАН 30
2.2. «Туган телдә сөйләшәбез» проекты 36
«Туган телдә сөйләшәбез». Комплекслы тематик план (2-3 яшь) 36
«Туган телдә сөйләшәбез» Комплекслы тематик план. Икенче кечкенәләр төркеме (3-4 яшь) 39
2.3. Эш төрләре һәм формалары 43
2.4. Коррекцион һәм инклюзив эш *(Кушымта №1)* 44
2.5. Татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү 45
2.6. Ата- аналар белән эш *(Кушымта №2)* 60
2.7. Педагогик коллектив белән эш *(Кушымта №3)* 60
2.8. Мәктәп белән бәйләнеш *(Кушымта №4)* 61
III НЧЕ ОЕШТЫРУ БҮЛЕГЕ 61
3.1. Татар телен өйрәтүдә кулланыла торган чаралар 61
3.2. Материаль - техник яктан тәэмин ителеш 69
3.3. Белем бирү эшчәнлеге челтәре 77
ӘДӘБИЯТ 79
КУШЫМТА 81

Кереш сүз

Балалар бакчасында рус балаларына татар теле өйрәтү буенча эш программасы (алга таба – Эш программасы) - мәктәпкәчә тәрбия һәм белем учреждениесендә рус һәм башка милләт балаларын татарча сөйләшергә, үзара һәм өлкәннәр белән аралашырга өйрәтү, төрле яктан үсеше өчен мөмкинлекләр тудыруга юнәлтелгән документ булып тора.

Эш программасы Федераль дәүләт белем стандартына (ФГОС) нигезләнеп төзелде, максат һәм бурычларны, көтелгән нәтиҗәләрне, белем бирү процессын оештыруны билгели.

Эш программасы мәктәпкәчә мәгариф системасы эшчәнлеген ачыклаучы норматив -хокукый актлар нигезләмәләренә көйләнгән.

Федераль җирлегендә:

- 29.12.2012елдан № 273-ФЗ « Россия Федерациясенең белем бирү турында» Федераль законы;
- Мәктәпкәчә мәгарифнең Федераль дәүләт белем стандарты (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013елның 17 октябрендә 1155 нче номерлы боерык нигезендә расланган);
- Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2022 елның 25 ноябрендәге 1028 номерлы боерыгы белән расланган Федераль мәктәпкәчә белем бирү программасы ;
- СанПиН 1.2.3685-21 « Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларының эш шартларын, режимын оештыру буенча санитар-эпидемиологик таләпләр» раслау турында Россия Федерациясе баш дәүләт табибы 2021 ел 28 гыйнвар 2 нче номырлы боерыгы;
- «Мәктәпкәчә мәгарифнең белем бирү эшчәнлеген төп гомуми белем бирү программалары нигезендә оештыру һәм тормышка ашыру» (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 ел 30 август 1014 нче номерлы боергы);

Төбәк җирлегендә:

- Татарстан Республикасының 2013ел 22 июль 68-ЗРТ номерлы «Белем бирү турында» Законы;
- Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында Татарстан Республикасының дәүләт телләре һәм башка телләр турында» Законы;

Мәктәпкәчә белем учреждениесе җирлегендә:

- МАМБУ Уставы;
- МАМБУнең төп белем бирү программасы турында нигезләмәсе;

Эш программасы өч бүлектән (максатчанлык, эчтәлекле, оештыру) тора, белем бирү өлкәләре буенча куелган бурычларны күздә тота.

1 НЧЕ МАКСАТЛАР БҮЛЕГЕ

1.1. Аңлатма язуы

«Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татар¬стан Республикасы Законында һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасында мәктәпкәчә милли белем бирү өчен кирәк¬ле шартлар булдыру каралган. Татарстан Республикасы Министр¬лар Кабинеты карары нигезендә кабул ителгән 2010-2015 елларда мәгарифне үстерү стратегиясендә (30.12.2010, № 1174) мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү учреждениеләре өчен рус һәм башка милләт балаларын татарча сөйләшергә өйрәтү программасы, укыту-методик комплектлары (УМК) төзү бурычы куелды.

Балалар бакчасында рус балаларына татар теле өйрәтү програм¬масы (алга таба программа) «Мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасы структурасына федераль дәүләт таләпләре»нә (РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының 23.11.2009 елда 655 нче карары) нигезләнеп төзелде.

Программа 4 яшьтән 7 яшькә кадәр булган рус телле балаларны татарча аралашырга өйрәтү эшчәнлекләрен үз эченә ала. Програм¬ма мәктәпкәчә яшьтәге баланың үсеш закончалыкларына, шәхси һәм эшлекле якын килү турындагы фундаменталь тикшеренүләргә, тел өйрәтү процессында методик стандарт итеп кабул ителгән коммуникатив технология принципларына, сөйләм барлыкка килү концепциясенә (Л. С. Выготский, В. В. Давыдов, Е. И. Пассов, П. Я. Гальперин), гамәли эшкәртмәләр һәм методик киңәшләргә, мәктәпкәчә мәгариф системасы эшчәнлеген ачыклый торган норма-тив-хокукый актлар, документларга нигезләнә.

1.1.1. Программаның максаты һәм бурычлары

Информацион – коммуникатив технологияләр, уен – ситуацияләр, күргәзмәлелек кулланып, тел өйрәтү, аралашу теләге тудыру.

Бурычлар: 1. Балаларның көнкүрешкә, табигатькә, җәмгыятькә кагылышлы сүзләр исәбенә сөйләмнәрен баету, сүз һәм сүзтезмәләрне төрле ситуацияләрдә кулланышка кертү.

2. Мөстәкыйль фикер йөртергә, җавап бирергә күнектерү, балада үзенең сөйләме белән кызыксыну һәм сизгерлек уяту.

3. Диалогик һәм монологик сөйләмне, хәтер, зиһен сәләтләрен үстерү.

4. Сөйләм әдәбе (сорау, гозер, мөрәҗәгать итү, рәхмәт белдерү, исәнләшү, саубуллашу) кагыйдәләрен, бер – береңне тыңлау, ишетү сыйфатлары, әдәпле итеп кара-каршы сөйләшә белү күнекмәләрен тәрбияләү.

1.1.2. Программаны формалаштыру принциплары һәм ысуллары

Коммуникативлык принцибы балаларны татар телен аралашу ча¬расы буларак куллануга әзерли. Телне фән буларак түгел, ә аралашу чарасы буларак өйрәтә.

Тел өйрәтү, тәрбия һәм үстерү бурычларының бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә тормышка ашырылу принцибы.

Дәвамчанлык принцибы балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәптә эзлеклелекне күздә тота.

Белем бирү эшчәнлегенең мотивлашкан булу принцибы - бала материалны үзе өчен кызык булганда, үзенең шәхси ихтыяҗларына туры килгәндә генә кабул итә һәм фикерли башлавында. Тел өйрәтү процессында әкияти сюжетлар карау, кызыклы таныш геройлар (Акбай, Мияу) белән очрашу, уен элементларын куллану тел материалын өйрәнүнең мотивлашкан булуын тәэмин итә. Телне аралашуга, уен ситуацияләренә бәйләп өйрәнгәндә, балалар тел өйрәнүнең практик әһәмиятен тоялар, эмоциональ күтәренкелек туа һәм алар тел мате¬риалын бик теләп үзләштерәләр.

Индивидуальләштерү принцибы тел өйрәткәндә социаль шәхес сыйфатларын үстерүне күздә тота. Балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә ала.

Күрсәтмәлелек принцибы тел өйрәтүне, көндәлек тормыштагы һәртөрле эшчәнлеккә бәйле рәвештә, балаларның тирә-юньне танып белүендә төп чара булып торган уен аша үткәрә.

Интеграция принцибы - һәр сөйләм төренең үзенчәлеген исәпкә алу, тәрбияче сөйләмен техник чаралар ярдәмендә (аудио-, видеояз-мада) тыңлау (аудирование), тел үзәнчәлекләрен төрле күнегүләрдә бирү, балаларның диалогик сөйләмен үстерү.Программа үзләштерүдә көтелгән нәтиҗәләр

1.2. Программаны үзләштерүнең нәтиҗәләре

«Татарча сөйләшәбез» проекты буенча максат ориентирлары
Уртанчылар төркеме (4-5 яшь) «Минем өем» проекты
Белем бирү эшчәнлегенең нәтиҗәләре

Ирешелгән нәтиҗәләр:

Өлкәннәр кушкан катлаулы булмаган биремнәрне аңлап, үти белә.

Тәрбияче әйткән сүзләрне, кыска фразаларны кабатлап әйтә белә.

Үз исемен дөрес әйтә, исәнләшә, саубуллаша, рәхмәт әйтә белә.

Куелган сорауларны аңлап, сөйләмдә 2-3 сүз белән җавап кайтара белә.

Бер-берсе һәм өлкәннәр белән 62 сүз кулланып татар телендә аралаша.

Бирелгән лексиканы төрле ситуацияләрдә ишетеп аңлап куллана белә, сөйләм күнекмәләре бар.

Татар телендә сөйләшү теләге бар.

Әйбер исемнәренең мәгънәсен аңлый һәм аларны дөрес әйтә белә.

Гаилә, уенчыклар, ашамлыклар һәм саннар хисабына сүз байлыгы бар.

Өйрәнгән сүзләрне аерым, күмәк, тәрбияче ярдәмендә кабатлый белә.

Бу кем? Бу нәрсә? сорауларын аңлап, җавап бирә.

Әйбернең билгесен ачыклау максаты белән куела торган сорауны аңлый һәм сөйләмдә җавап кайтара белә.

Тәрбияче әйткән сүзләрне, кыска фразаларны кабатлап әйтә. Өлкәннәр кушкан катлаулы булмаган биремнәрне аңлап үти.

Тәрбияче әйткән билге буенча предметны таба, күрсәтә белә.

Үз исемен дөрес әйтә, исәнләшә, саубуллаша белә, сүзләрне дөрес, урынлы куллана.

Куелган сорауга раслаучы, инкарь итүче сүзләрне дөрес кулланана белә.

Мин, син алмашлыкларын аңлый һәм урынлы куллана.

Кечкенә күләмле шигырьләр, җырлар белә.

Тәрбияче һәм ата- аналар белән берлектә ирешергә кирәк нәтиҗәләр:

Сүз байлыгы аз.
Бирелгән лексиканы ишетеп аңлый, куллана белми.
Сорауларны аңлый, җавап бирә алмый.
Мин, син алмашлыкларын урынлы куллана белми.

Зурлар төркеме (5-6 яшь) “Уйный – уйный үсәбез” проекты

Белем бирү эшчәнлегенең нәтиҗәләре

Ирешелгән нәтиҗәләр:

Гади сорауларны аңлап җавап бирү, мөрәҗәгать итә белә.

Үзара һәм зурлар белән көндәлек тормышта107 сүз кулланып татар телендә аралаша.

Сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә куллана.

Боерык фигыльләрне сөйләмдә аңлап, дөрес куллана.

“Уйный-уйный үсәбез” проекты темалары (“Гаилә”, “Ашамлыклар”, “Уенчыклар”, “Саннар” **, “**Яшелчәләр”, “Савыт-саба”, “Киемнәр”, “Шәхси гигиена”, “Өй җиһазлары”, “Бәйрәмнәр”) буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (уен, аралашу, музыка, хезмәт, хәрәкәт) ишетеп аңлап куллана белә, сөйләм күнекмәләре бар.

Яңа сүзләр хисабына сүз байлыгы бар.

Санау күнекмәләре бар, сөйләмдә куллана белә.

Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә.

Раслаучы һәм инкарь итүче сүзләрне аңлый, урынлы куллана.

Исем + сыйфат конструкциясен сөйләмдә дөрес куллана.

Боерык фигыльләрне сөйләмдә аңлап дөрес куллана белә.

Алган белемнәрен, сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә куллана белә.

Тәрбияче һәм ата- аналар белән берлектә ирешергә кирәк нәтиҗәләр:

Сүз байлыгы аз.

Бирелгән лексиканы ишетеп аңлый, куллана белми.

Сорауларны аңлый, мөстәкыйль рәвештә сорау куя белми.

Сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә куллана алмый.

Мәктәпкә әзерлек төркеме (6-7 яшь) “Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар”проекты

Белем бирү эшчәнлеге нәтиҗәләре

Ирешелгән нәтиҗәләр:

Сөйләмне аралашу чарасы буларак файдалана белә.

Диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләре бар.

Мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белә.

Бер-берсе һәм өлкәннәр белән 167 сүз кулланып татар телендә актив аралаша.

“Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар” проекты темалары (“Гаилә”, “Ашамлыклар”, “Уенчыклар”, “Саннар” , “Яшелчәләр”, “Савыт-саба”, “Киемнәр”, “Шәхси гигиена”, “Өй җиһазлары”, “Бәйрәмнәр”, “Танышу”, “Тату гаилә”, “Дусларны сыйлыйбыз”, “Кунак килде”, “Кафега барабыз”, “Күңелле уеннар”, “Без циркта”, “Безнең дуслар”, “Чана шуабыз”, “Без биибез”, “Күңелле сәяхәт”, “Мәктәп”, “Без әкият яратабыз”) буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (танып – белү, уен, аралашу, музыка, хезмәт, хәрәкәт) ишетеп аңлап куллана белә, сөйләм күнекмәләрен бар.

Яңа сүзләр хисабына сүз байлыгы бар.

Бу кем? Бу нәрсә? Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Нишли? Син нишлисең? Кая барасың? соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белә.

Фигыльләрне урынлы куллана.

Җырлар, шигырьләр белә.

Тәрбияче һәм ата- аналар белән берлектә ирешергә кирәк нәтиҗәләр:

Яңа сүзләр хисабына сүз байлыгы аз.

Бирелгән лексиканы диалогик һәм монологик сөйләмдә куллана алмый.

“Бу кем?”, “Бу нәрсә?”, “Нәрсә кирәк?”, “Нинди?”, “Ничә?”, “Нишли?”, “Син нишлисең?” “Кая барасың?” сорауларын мөстәкыйль рәвештә куя белми. Фигыльләрне урынлы куллана белми.

«Туган телдә сөйләшәбез» проекты буенча максат ориентирлары
Беренче кече яшьтәгеләр төркеме (2-3 яшь) «Туган телдә сөйләшәбез»

Белем бирү эшчәнлеге нәтиҗәләре

Ирешелгән нәтиҗәләр:

1. Баланың сүзлек запасы

Бала предметларның исемен дөрес атый, төсләрне дөрес билгели. Тәрбиячененң сорауларына теләп, ышанычлы итеп җавап бирә.

2. Сөйләмнең грамматик ягы

Бала биремнәрне дөрес үти. Тәрбиячененң сорауларына җавап биргәндә, исем белән фигыльне, алмашлык белән фигыльне яраклаштыра ала. Тәрбиячененң сорауларына теләп, ышанычлы итеп җавап бирә.

3. **Сөйләмнең аваз культурасы**

Бала биремнәрне теләп башкара, аваз ияртемнәрен дөрес һәм ачык итеп әйтә.

4. Бәйләнешле сөйләм

Бала гади (кем? нәрсә?) һәм катлаулы (кемгә? нинди? кайчан? кайда? кая?) сорауларга җавап бирә. Үз инициативасы белән яки тәрбияче кушуы буенча, рәсемдә сурәтләнгәнне сөйли ала.

Тәрбияче һәм ата- аналар белән берлектә ирешергә кирәк нәтиҗәләр:

1. Баланың сүзлек запасы

Бала, предметларның исемен атаганда, төсләрен билгеләгәндә, хаталар җибәрә. Тәрбиячененң сорауларына җавап бирә алмый .

Бала предметларның исемен дөрес атый, төсләрен билгеләгәндә, хаталар җибәрә. Тәрбиячененң сорауларына өстәмә сораулар ярдәмендә генә җавап бирә.

2. Сөйләмнең грамматик ягы

Бала биремнәрне үти алмый. Тәрбиячененң сорауларына җавап бирә алмый. Тәрбияче актив ярдәм күрсәткәндә дә, хаталар ясый . Бала биремнәрне үтәргә тырыша, тәрбиячененң сорауларына бер сүз белән генә җавап бирә.

3. Сөйләмнең аваз культурасы

Бала 1—2 биремне генә үти ала.

Бала биремнәрне тәрбияче ярдәме белән башкара, аның артыннан кабатлый.

4. Бәйләнешле сөйләм

Бала сорауларга ишарәләр яки бер сүз белән генә җавап бирә .

Бала, җавап биргәндә, 2—3 сүздән торган гади җөмләләргә өстенлек бирә.

Икенче кече яшьтәгеләр төркеме (3-4 яшь) «Туган телдә сөйләшәбез»

Белем бирү эшчәнлеге нәтиҗәләре

Ирешелгән нәтиҗәләр:

1. Баланың сүзлек запасы

Предметларның исемен дөрес атый, гомумиләштерүче сүзләрне дөрес билгели

2.   Сөйләмнең грамматик ягы

Тәрбиячененң сорауларына җавап биргәндә, җөмләләрне грамматик яктан дөрес төзи. Җөмләләрнең иясе һәм хәбәре бар. Тәрбиячененң сорауларына теләп, ышанычлы итеп җавап бирә.

3.   Сөйләмнең аваз культурасы

Бала биремнәрне теләп башкара. Аваз ияртемнәрен дөрес һәм ачык итеп әйтә.

4. Бәйләнешле сөйләм

Бала гади (кем? нәрсә?) һәм катлаулы (кемгә? нинди?

кайчан? кайда? кая?) сорауларга җавап бирә. Үзенең инициативасы яки тәрбиячененң үтенече буенча рәсемдә сурәтләнгәнне сөйли ала. Әкиятнең эчтәлеген сөйләгәндә эзлеклелекне саклый, сәхнәләштерүдә теләп катнаша.

Тәрбияче һәм ата- аналар белән берлектә ирешергә кирәк нәтиҗәләр:

1. Баланың сүзлек запасы

Предметларның исемен атаганда авырлыклар кичерә, гомумиләштерүче сүзләрне куллана алмый.

Предметларның исемен дөрес атый, гомумиләштерүче сүзләрне белдергәндә хаталар җибәрә.

2. Сөйләмнең грамматик ягы

Бала биремнәрне үти алмый. Тәрбияченең сорауларына җавап бирә алмый. Тәрбияче актив ярдәм күрсәткәндә дә, хаталар ясый.

Бала биремнәрне үтәргә тырыша, тәрбияченең сорауларына бер сүз белән генә җавап бирә.

3. Сөйләмнең аваз культурасы

Бала 1-2 биремне генә үти ала.

Бала биремнәрне тәрбияче ярдәме белән башкара,аның артыннан кабатлый.

4. Бәйләнешле сөйләм

Бала гади (кем? нәрсә?) һәм катлаулы (кемгә? нинди? кайчан? кайда? кая?) сорауларга җавап бирә. Үзенең инициативасы яки тәрбиячәнең үтенече буенча рәсемдә сурәтләнгәнне сөйли ала. Әкиятнең эчтәлеген сөйләгәндә эзлеклелекне саклый, сәхнәләштерүдә теләп катнаша.

Уртанчылар төркеме (4-5 яшь) «Туган телдә сөйләшәбез»

Белем бирү эшчәнлеге нәтиҗәләре

Ирешелгән нәтиҗәләр:

Бала дөрес, төгәл, мөстәкыйль җавап бирә.

Тәрбияче һәм ата- аналар белән берлектә ирешергә кирәк нәтиҗәләр:

Тәрбиячәнең этәргеч сораулары буенча җавап бирә һәм зур булмаган төгәлсезлекләр җибәрә.

Баланың җаваплары зурлар биргән сорауга туры килми, сүзләрне тәрбияче артыннан кабатлый, сорауны аңламый.

Зурлар һәм мәктәпкә әзерлек төркеме (5 - 7яшь) «Туган телдә сөйләшәбез»

Белем бирү эшчәнлеге нәтиҗәләре

Ирешелгән нәтиҗәләр зурлар төркеме:

Танып белү

Бала транспорт төрләрен, кеше тормышын җиңеләйтә, уңайлыклар тудыра торган әйберләрне таный һәм әйтә. Предмет һәм аның үзенчәлекләре (төсе, формасы, күләме, нинди материалдан булуы) турында сөйли, аларны төркемли белә. Төзүче, транспорт хезмәткәрләре, авыл эшчәннәре хезмәте турында белә. Юл йөрү кагыйдәләрен дөрес әйтә. Туган иле, шәһәре (авылы), Россиянең, Татарстанның башкаласы турында белә. Үз туганнары, үзе турында сөйли, адресын әйтә. Табигатьтәге кайбер закончалыкларны белә, алар арасындагы бәйләнешләр турында нәтиҗә чыгара.

Аралашу

Сөйләмдә төрле кушма җөмләләр куллана белә, туры һәм кыек сөйләмнән файдалана. Үз тәҗрибәсеннән чыгып, эчтәлекле рәсемнәр, картиналар буенча мөстәкыйль рәвештә хикәя төзи. Әдәби әсәрләрнең эчтәлеген сөйләгәндә, иҗади хикәяләр төзегәндә интонацияләрдән дөрес файдалана. Сөйләмдә, башкалар белән аралашканда ягымлы сүзләр куллана белә. Мәгънәдәш сүзләр, капма-каршы сүзләрне дөрес әйтә белә. Тәрбияче һәм балалар белән аралашуда теләп катнаша. Үстерешле аралашуда катнашу дәрәҗәсе камил.

Матур әдәбият уку

Әсәрнең жанрын (әкият, хикәя) аера ала. Зур булмаган әсәрләрне сәхнәләштерүдә, рольләргә бүлеп шигырьләр укуда актив катнаша, тиз истә калдырып, яттан сөйли. Язучыларны таный һәм атый, әсәрләрен белә. Шигырьләрне, мәкальләрне, санамышларны сөйләмдә мөстәкыйль куллана. Әдәби персонажларның кылган гамәлләренә дөрес бәя бирә. Үзенең яраткан китабы турында башкаларга сөйләп бирә ала.

Тәрбияче һәм ата- аналар белән берлектә ирешергә кирәк нәтиҗәләр:

Танып белү

Бала транспорт төрләрен, кеше тормышын җиңеләйтә, уңайлыклар тудыра торган әйберләрне атаганда хата җибәрә, ләкин үзлектән төзәтә. Предмет һәм аның үзенчәлекләре (төсе, формасы, күләме, нинди материалдан булуы) турында

тулысынча сөйләми, исенә төшергәч, өстәп сөйли белә, төркемли ала. Төзүче, транспорт хезмәткәрләре, авыл эшчәннәре хезмәте турында мәгълүматны тулысынча биреп бетерә алмый. Туган иле, шәһәре (авылы), Россиянең, Татарстанның башкаласы турында белә. Үз туганнары, үзетурында аз сөйли, сораулар биргәч, үзлектән тулыландыра. Табигатьтәге кайбер закончалыкларны аңлатканда, үзара бәйләнешләр турында нәтиҗә чыгарганда кыенлыклар кичерә.

Бала транспорт төрләрен, кеше тормышын җиңеләйтә, уңайлыклар тудыра торган әйберләрне атаганда хата җибәрә. Предмет һәм аның үзенчәлекләре (төсе, формасы, күләме, нинди материалдан булуы) турында тәрбияче ярдәменнән башка сөйли белми, төркемли алмый. Төзүче, транспорт хезмәткәрләре, авыл эшчәннәре хезмәте турында мәгълүматы юк. Туган иле, шәһәре (авылы), Россиянең, Татарстанның башкаласы турында әйтә белми. Үз туганнары, үзе турында тәрбияче ярдәмендә сөйли. Адресын белми. Табигатьтәге кайбер закончалыкларны аңлата, үзара бәйләнешләр турында нәтиҗә чыгара алмый.

Аралашу

Сөйләмдә төрле кушма җөмләләр кулланганда хаталар җибәрә, үзлектән төзәтә белә. Үз тәҗрибәсеннән чыгып, эчтәлекле рәсемнәр, картиналар буенча хикәя төзегәндә тәрбияче ярдәмен көтә, бик үк мөстәкыйль түгел. Әдәби әсәрләрнең эчтәлеген тулы бирми, иҗади хикәяләр төзегәндә иҗади түгел. Сөйләмдә, башкалар белән аралашканда, ягымлы сүзләрне аз куллана. Мәгънәдәш сүзләр, капма-каршы сүзләрне әйткәндә хаталар җибәрә. Тәрбияче һәм балалар белән аралашуда катнаша, үстерешле аралашуда катнашуы камил дәрәҗәдә түгел.

Бала сөйләмдә гади җөмләләр куллана, үз тәҗрибәсеннән чыгып, начар сөйли, эчтәлекле рәсемнәр, картиналар буенча хикәя төзегәндә тәрбияче ярдәмен көтә. Әдәби әсәрләрнең эчтәлеген план буенча сөйли белми, иҗади хикәяләренең эчтәлеге гади, интонацияләрдән файдаланмый. Сөйләмдә, башкалар белән аралашканда ягымлы сүзләрне аз куллана. Мәгънәдәш сүзләр, капма-каршы сүзләрне әйтми. Тәрбияче һәм балалар белән аралашуда сирәк катнаша, үстерешле аралашуда катнашуы юк дәрәҗәдә.

Матур әдәбият уку

Әсәрнең жанрын (әкият, хикәя) аерганда ялгышлыклар җибәрә, ләкин тәрбияче ярдәмендә үзлектән төзәтә ала. Зур булмаган әсәрләрне сәхнәләштерүдә, рольләргә бүлеп шигырьләр укуда активлык күрсәтми, ләкин катнаша. Язучыларны таный, әсәрләрен әйтүдә кыенлыклар кичерә. Шигырьләрне, мәкальләрне, санамышларны сирәк куллана. Әдәби персонажларның кылган гамәлләренә бәя биргәндә, хаталар җибәрә. Үзенең яраткан китабы турында башкаларга тулы итеп сөйләми.

Әсәрнең жанрын (әкият, хикәя) аера алмый. Зур булмаган әсәрләрне сәхнәләштерүдә, рольләргә бүлеп шигырьләр укуда катнашырга теләге юк. Язучыларны танымый, әсәрләрен әйтә алмый. Шигырьләрне, мәкальләрне, санамышларны кулланмый. Әдәби персонажларның кылган гамәлләренә бәя бирә белми. Үзенең яраткан китабы турында башкаларга сөйли белми.

1.3. Программаны үзләштерүнең педагогик диагностикасы

МББ ФДББС белән ярашлы рәвештә максат ориентирлары турыдан-туры, шул исәптән педагогик диагностика (мониторинг) рәвешендә дә, бәяләүгә алынмый һәм аларны балаларның реаль казанышлары белән формаль чагыштыру өчен нигез була алмый. Алар балаларның әзерлегенә һәм белем бирү эшчәнлегенә карата кабул ителгән таләпләргә туры килә торган объектив бәяләмәнең асылы булып тормый. Программаны үзләштерү арадаш аттестацияләр һәм тәрбияләнүчеләрнең йомгаклау аттестациясен уздыру белән кушылып китми. МББнең ФДББСннан күренгәнчә, максат ориентирлары идарә итү бурычларын хәл иткәндә турыдан-туры нигез була алмыйлар. Әлеге бурычларга түбәндәгеләр керә:

• педагогик кадрларны аттестацияләү;

• белем бирүнең сыйфатын бәяләү;

• балаларның соңгы, шулай ук арадаш үсеш дәрәҗәсен, шул исәптән мониторинг кысаларында бәяләү (шул исәптән күзәтүгә яисә балаларның нәтиҗәгә ирешүен тикшерүнең башка ысулларына нигезләнгән методлар кулланып тестлар уздыру формасында);

• максат ориентирларын биремне үтәүнең сыйфат күрсәткеченә кертү ярдәмендә муниципаль (дәүләт) биремнәренең башкарылуын бәяләү;

• оешма хезмәткәрләре хезмәтенә түләүнең стимуллаштыручы фондын билгеләү.

Әмма педагог үз эше барышында һәрбер баланың индивидуаль үсеш траекториясен булдырырга тиеш. Моның өчен педагогка үз эшен бәяләүнең балалар белән иң уңайлы рәвештә үзара бәйләнеш булдырырга ярдәм итүче инструментарие кирәк.

Тәкъдим ителгән Программаны үзләштерү нәтиҗәләрен бәяләү системасында мәктәпкәчә белем бирүнең сыйфатын бәяләүне аңлауның үзгәрүе белән бәйле заманча тенденцияләр чагылыш таба. Беренче чиратта, игътибарны әкренләп объектив (тестлар уздыру) якын килүдән аутентик бәяләү ягына күчерү турында сүз бара. Тамырлары белән стандартлаштырылган тест традицияләренә китеп, объектив якын килү кысаларында тикшеренүләр махсус бурычларны хәл

итү барышында балалардагы аерымлыкларны (еш кына җитешсезлекләрне) билгеләүгә юнәлтелгән иде. Әлеге тестлар килеп чыккан нәтиҗәләрне норма белән чагыштырырга мөмкинлек тудыра, шуның белән һәрбер баланың үз яшьтәшләре белән чагыштырганда үсеше турында мәгълүмат бирә. Шунлыктан мондый тестлар педагогик хәвефлелек төркеменә керергә тиешле балаларны ачыклауда киң кулланыла.

Әлеге ысулның төп җитешсезлеге шунда: ясалма биремнәр еш кына балаларның көндәлек тормышыннан шактый ерак, шуңа күрә алар мәктәпкәчә яшьтәге балаларның реаль мөмкинлекләрен тулысынча чагылдыра алмыйлар. Тест ысулы балаларның социаль даирәсе үзенчәлекләрен исәпкә алмый, һәм аның нәтиҗәләренә корылган фаразлар да шактый шартлы.

Аутентик бәяләүнең нигезендә түбәндәге принциплар ята. Беренчедән, асылда ул махсус биремнәрне үтәү нәтиҗәсенә түгел, баланың реаль тәртибен анализлауга карап корыла. Мәгълүмат турыдан-туры баланың тәртибен күзәтү ярдәмендә туплана. Күзәтү нәтиҗәләрен педагог гадәти тестларда куллана торган, мәктәпкәчә яшьтәге баланың реаль тормышына кагылышы аз булган уйлап чыгарылган ситуацияләрдә түгел,табигый мохиттә (уеннар вакытында, режим моментлары барышында, дәресләрдә) таба.

Икенчедән, әгәр тестларны махсус өйрәтелгән профессиональ белгечләр (психологлар, медицина хезмәткәрләре һ.б.) уздырса, аутентик бәяне исә бала белән озак вакыт булган, аның тәртибен яхшы белгән өлкәннәр куя ала. Бу очракта педагог тәҗрибәсе бәяләп бетергесез.

Өченчедән, аутентик бәя югары дәрәҗәдә структурлашкан. Ниһаять, әгәр тестлар ярдәмендә бәя кую очрагында ата-аналар алынган мәгълүматларның мәгънәсен һәрвакытта да аңлап бетермәсәләр һәм шуңа да еш кына балаларга тест уздыруга тискәре мөнәсәбәт күрсәтсәләр, аутентик бәяләү вакытында җаваплар аларга аңлаешлы. Ата-аналар теге яисә бу сорауга җавап эзләгәндә педагогның партнерлары булып китәргә мөмкин.

2 НЧЕ ЭЧТӘЛЕК БҮЛЕГЕ

2.1. «Татарча сөйләшәбез» проекты

Уртанчылар төркеме (4-5 яшь) «Минем өем» проекты

Белем бирү эшчәнлегенең бурычлары

1.Тирә- юнь күзаллавын киңәйтә барып, иң якын кешеләре, уенчыклар, ашамлыклархисабына сүз байлыгын арттыру.
2.Өлкәннәр кушкан катлаулы булмаган биремнәрне аңлап, үти белүләренә ирешү.
3.Тәрбияче әйткән сүзләрне, кыска фразаларны кабатлап әйтә белүләренә ирешү.
4.Үз исемен дөрес әйтә, исәнләшә, саубуллаша, рәхмәт әйтә белү күнекмәләрен үстерү.
5.Куелган сорауларны аңлап, сөйләмдә 2-3 сүз белән җавап кайтару күнекмәләрен үстерү.

Белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге

Лексик минимум – якынча 62 сүз.
"Минем өем" проекты темалары ("Гаилә","Ашамлыклар","Уенчыклар","Саннар") буенча бирелгән лексиканы төрле ситуацияләрдә ишетеп аңлап куллана белергә өйрәтү, сөйләм күнекмәләрен булдыру.
Аларның тирә-юнь күзаллавын киңәйтә бару, югарыда күрсәтелгән темага караган сүзләр хисабына балаларның сүз байлыгын арттыру өстендә эшләү, аларда татар телендә сөйләшә башлау теләге уяту.
Актив үзләштерүләренә ирешү өчен әйбер исемнәренең мәгънәсен аңлату һәм аларны дөрес әйтү күнегүләре эшләү. Иң якын кешеләр *(әти, әни, бабай, әби, малай, кыз)*, яраткан уенчыклар (*туп, машина, курчак, эт, песи куян, аю),* ашамлыклар *(алма, ипи, сөт, чәй)* һәм саннар *(бер, ике, өч, дүрт, биш)* хисабына сүзлекне баету һәм активлаштыру. Өйрәнгән сүзләрне аерым, күмәк, тәрбияче ярдәмендә кабатлый белү күнекмәләрен булдыру. *Алма бир. Мә, алма*.
Бу кем? Бу нәрсә? сорауларын аңлап җавап бирергә өйрәтү.
-*Бу кем? – Бу әти.*
-*Бу нәрсә? – Бу туп.*
Нинди? соравын аңларга, дөрес җавап бирергә өйрәтү.
-*Туп нинди? – Кечкенә.*
-*Машина нинди? – Матур.*
Әйбернең билгесен ачыклау максаты белән куела торган сорауларны аңларга һәм сөйләмдә җавап кайтарырга өйрәтү. (Зур, матур, кечкенә, чиста, әйбәт, пычрак, тәмле).

-*Бу нәрсә? – Бу туп.*
-*Туп нинди? – Туп пычрак (зур, матур, кечкенә, чиста, әйбәт).*
Тәрбияче әйткән сүзләрне, кыска фразаларны балаларның кабатлап әйтә белүләренә ирешү өстендә эшләү. Аларның өлкәннәр кушкан катлаулы булмаган биремнәрне аңлап, үти белүләренә ирешү *(мә, бир, утыр, аша, эч, уйна, ю, ал).*
-*Мә, куян. – Бир куян.*
Тәрбияче әйткән билге буенча предметны табу, күрсәтә белергә өйрәтү.
Зур машина ал. Тәмле алма бир.
Үз исемен дөрес әйтә, исәнләшә, саубуллаша белергә өйрәтү, сүзләрне дөрес, урынлы куллану.
Исәнме. – Исәнмесез. Сау бул. – Сау булыгыз. Мин кыз. - *Мин Оля. Мин малай* - *Мин Коля.*
Таныш предметларның исемнәрен ныгыту, куелган сорауга раслаучы, инкарь итүче сүзләрне *(әйе, юк)* дөрес кулланырга өйрәтү
Син Коля? – Әйе.
Син кыз? – Юк, мин малай.
Мин, син алмашлыкларын аңларга һәм урынлы кулланырга өйрәтү.
Син кем? – Мин Коля.
Кечкенә күләмле шигырьләр, җырлар өйрәтү.

УРТАНЧЫЛАР ТӨРКЕМЕ «МИНЕМ ӨЕМ» ПРОЕКТЫ БУЕНЧА ТЕМАТИК ПЛАН

АКТИВ СҮЗЛӘР	**СӨЙЛӘМ ҮРНӘГЕ**	**АУДИОЯЗМА ЭШ ДӘФТӘРЕ АНИМАЦИОН СЮЖЕТ**
ГАИЛӘ – 12 СӘГАТЬ		
әти әни малай кыз	-Бу кем? -Әти (әни, бабай, әби, кыз, малай). -Кем юк? -Әти (әни, бабай, әби, малай, кыз).	Аудиоязма №1-23 Дәфтәрдә эш №1-4 Сюжетлар: 1. “Әйдәгез, дуслашыйк”

мин исәнмесез сау булыгыз	-Исәнмесез. -Син кем? -Мин Коля (Оля). -Мин малай. -Сау булыгыз!	2. “Качышлы уйныйбыз” 3. “Шалкан”
исәнме	-Исәнме, әни (әти, бабай, әби, кыз, малай, Мияу, Акбай). -Сау бул, әни (әти, бабай, әби, кыз, малай).	
 эт песи	-Кем анда? -Мин песи. Мин Мияу. -Кил монда. -Мин эт. Мин Акбай. -Кил монда.	
 әйе юк сау бул	-Син Коля? -Әйе, Коля. -Син малай (кыз)? -Әйе (юк).	
 әби бабай	-Әти? (әни, бабай, әби, кыз, малай). -Әйе. -Әни? (әти, бабай, әби, кыз, малай). -Юк.	
	-Малай? -Юк, кыз. -Кыз? -Әйе, кыз.	

әйбәт	-Хәлләр ничек? -Әйбәт.	
АШАМЛЫКЛАР – 9 СӘГАТЬ		
ипи алма сөт чәй мә рәхмәт тәмле кил монда утыр аша эч	-Мә, ипи (алма, сөт, чәй). -Рәхмәт, әби. -Коля, мә ипи (алма, сөт, чәй). -Рәхмәт. -Мияу, кил монда. Утыр. (Акбай, Коля, Оля) -Оля, кил монда. Мә ипи (алма, сөт, чәй). Ипи (алма, сөт, чәй) тәмле (ме)? -Ипи (алма, сөт, чәй) тәмле. Рәхмәт. -Мә, тәмле алма (ипи). -Мә, ипи (алма) аша. -Мә, сөт (чәй) эч.	Аудиоязма №24-39 Дәфтәрдә эш №5-10 Сюжетлар: 1.“Тәмле” кибетендә” 2. “Азат кунак чакыра”
УЕНЧЫКЛАР – 17 СӘГАТЬ		
бир туп зур	- Бу нәрсә? - Туп (курчак, куян, аю). -Курчак (туп, куян, аю) бир.	Аудиоязма №40-53 Дәфтәрдә эш №11-13

кечкенә матур курчак куян аю хәлләр ничек?	-Мә, курчак (туп, куян, аю). -Бу нәрсә? -Аю (курчак, куян, туп). -Аю (курчак, куян, туп) нинди? -Аю (курчак, куян, туп) зур (матур, кечкенә, әйбәт). - Аю (курчак, куян, туп) нинди? - Аю (курчак, куян, туп) зур (кечкенә, матур, әйбәт). -Аю (курчак, куян, туп)? -Әйе. -Курчак (аю, куян, туп)? -Юк. -Бу нәрсә? -Аю (курчак, куян, туп). -Мә, аю (курчак, куян, туп). Уйна. -Коля, кил монда. Уйна. -Оля, кил монда. Уйна. - Аю (курчак, куян, туп) бир. - Аю (курчак, куян, туп) нинди? - Аю (курчак, куян, туп) зур. - Аю (курчак, куян, туп) кечкенә. - Мә, зур аю (курчак, куян, туп). - Мә, кечкенә аю (курчак, куян, туп).	Сюжетлар: 1. “Паркка сәяхәт” 2. “Уенчыклар үпкәләгән” 3. “Күңелле уеннар” 4. “Акбай һәм Мияу мажаралары”

<table>
<tr><td>уйна

пычрак
чиста

ю</td><td>-Аю (курчак, куян), кил монда. Аша (утыр, эч, уйна).

-Коля (Оля), аю (курчак, куян, туп) ю.

-Туп (курчак, куян, аю) нинди?
-Туп (курчак, куян, аю) пычрак (чиста).
-Туп ю.
- Туп чиста?
- Юк, туп пычрак.
(Әйе, туп чиста).
Ю, ю, ю – туп (курчак, аю, куян) ю.</td><td></td></tr>
<tr><td colspan="3">САННАР - 6 СӘГАТЬ</td></tr>
<tr><td>бер
ике
өч
дүрт
биш</td><td>-Ничә?
-Бер (ике, өч, дүрт, биш) алма.

-Ничә малай?
-Бер (ике, өч, дүрт, биш) малай.
-Ничә кыз?
-Бер (ике, өч, дүрт, биш) кыз.

-Өч?
-Юк.
-Ике?
-Әйе.

-Ничә аю (туп, курчак, куян)?
-Бер (ике, өч, дүрт, биш) аю.</td><td>Аудиоязма №54-60
Дәфтәрдә эш №14
Сюжет:
1.“Уйный-уйный саныйбыз”</td></tr>
<tr><td colspan="3">КАБАТЛАУ - 12 СӘГАТЬ</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td>Аудиоязма №61-64
Дәфтәрдә эш №16-17</td></tr>
</table>

		Сюжет: 1. “Күңелле ял итәбез”
ЙОМГАКЛАУ - 9 СӘГАТЬ		

Зурлар төркеме (5-6 яшь) «Уйный – уйный үсәбез» проекты

Белем бирү эшчәнлегенең бурычлары

1. Тирә- юнь күзаллавын киңәйтә барып, яшелчәләр, савыт-сабалар, киемнәр, өй җиһазлары, ашамлыклар темасына кергән сүзләр хисабына сүз байлыгын арттыру.
2. Гади сорауларны аңлап җавап бирү, мөрәҗәгать итә белүләренә ирешү.
3. Үзара һәм зурлар белән көндәлек тормышта татарча аралашуга чыгуларына ирешү.
4. Сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә камилләштерү.
5. Боерык фигыльләрне сөйләмдә аңлап дөрес куллана белү күнекмәләрен үстерү.

Белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге

Лексик минимум – якынча 45 сүз.

“Уйный-уйный үсәбез” проекты темалары (“Гаилә”, “Ашамлыклар”, “Уенчыклар”, “Саннар” **, “**Яшелчәләр”, “Савыт-саба”, “Киемнәр”, “Шәхси гигиена”, “Өй җиһазлары”, “Бәйрәмнәр”) буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (уен, аралашу, музыка, хезмәт, хәрәкәт) ишетеп аңлап куллана белергә өйрәтү, сөйләм күнекмәләрен булдыру.

Яңа сүзләр хисабына баланың сөйләмен баету, тулыландыру. (*Кишер, суган, бәрәңге, кыяр, кәбестә, аш, ботка, кашык, тәлинкә,чынаяк, күлмәк, чалбар, бит, кул, өстәл урындык, карават, баллы, ничә, нинди, алты, җиде, сигез, тугыз, ун, кызыл, сары, яшел, зәңгәр, нәрсә кирәк, юа, ки, сал, йокла, хәерле көн, яратам, бар).*

Санау күнекмәләрен ныгыту, сөйләмдә камилләштерү.

Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белергә өйрәтү.

Раслаучы һәм инкарь итүче сүзләрне ныгыту, урынлы куллану. *(Әйе, юк)*

Исем + сыйфат конструкциясен сөйләмдә активлаштыру.

- *Бу кызыл тәлинкә.*

“Минем өем” проекты буенча өйрәнелгән боерык фигыльләрне ныгыту *(аша, эч, утыр, ю, уйна, йокла)*, яңа боерык фигыльләрне *(ки, сал)* сөйләмдә аңлап дөрес куллана белергә өйрәтү, активлаштыру.

Алган белемнәрен, сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә камилләштерү.

ЗУРЛАР ТӨРКЕМЕ

«УЙНЫЙ-УЙНЫЙ ҮСӘБЕЗ» ПРОЕКТЫ БУЕНЧА ТЕМАТИК ПЛАН

АКТИВ СҮЗЛӘР	СӨЙЛӘМ ҮРНӘГЕ	АУДИОЯЗМА ЭШ ДӘФТӘРЕ АНИМАЦИОН СЮЖЕТ
КАБАТЛАУ – 2 СӘГАТЬ		
	“Минем өем” проекты буенча	Аудиоязма №1 Дәфтәрдә эш №1 Сюжет: 1. “Шалкан”
ЯШЕЛЧӘЛӘР – 21 СӘГАТЬ		
кишер баллы ничә суган бәрәңге	-Бу нәрсә? -Кишер. -Мә, кишер. -Нинди кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)? -Зур (кечкенә) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) -Мә, зур (кечкенә) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) -Рәхмәт.	Аудиоязма №2-24 Дәфтәрдә эш №2-6 Сюжетлар: 1.“Баллы кишер” 2. “Уйный-уйный эшлибез” 3. “Юл мажаралары” 4. “Кем эшләми, шул ашамый”

кыяр кәбестә нинди алты җиде сигез тугыз ун	-Зур кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) -Кечкенә кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) -Чиста кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) -Пычрак кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) -Кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) нинди? -Кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) тәмле, зур (кечкенә), матур, чиста (пычрак) Кишер баллы. Алма баллы. -Мә кишер(алма), аша. Баллы? -Әйе, баллы. Рәхмәт. -Ничә кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)? Сана. -Ике (1-10) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) -Оля, кил монда. Мә, ике (1-10) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) -Ике (1-10) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) -Оля, кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер) бир. -Мә, кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә,кишер). -Рәхмәт. -Коля, (1-10) кәбестә (суган, бәрәңге, кишер, кыяр) бир. -Мә, (1-10) кәбестә (суган, бәрәңге, кишер, кыяр). -Сау бул, Коля. -Ничә кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер)?	

кызыл сары яшел нәрсә кирәк? юа	-Бер (1-10) кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер). -Кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер) пычрак. -Бу туп. -Туп (алма) нинди? -Туп (алма) сары (кызыл, яшел) -Нинди туп (алма) юк? -Кызыл (сары, яшел) туп (алма) юк. -Кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) кирәк? -Кирәк. -Коля, нәрсә кирәк? -Кыяр (суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) кирәк. -Нинди кыяр? -Яшел (тәмле, чиста) кыяр. -Кыяр (суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) пычрак. -Мә, кыяр (суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) ю. -Оля кыяр (суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) юа.	
АШАМЛЫКЛАР – 7 СӘГАТЬ		
аш ботка	тәмле аш (ботка, сөт, ипи, чәй) -Нәрсә кирәк? -Аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге) кирәк. -Нинди аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге)?	Аудиоязма №25-29 Дәфтәрдә эш №7, 8 Сюжет: 1.“Аш бүлмәсе”

	-Тәмле аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге). -Мә, аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге) аша (эч). -Рәхмәт. Аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге) тәмле.	
САВЫТ-САБА - 6 СӘГАТЬ		
кашык тәлинкә чынаяк зәңгәр	-Кашык (тәлинкә, чынаяк) бир. -Нинди кашык (тәлинкә, чынаяк)? -Зур (кечкенә, сары, яшел, кызыл, зәңгәр). -Ничә кашык (тәлинкә, чынаяк)? -(1-10 га) кашык (тәлинкә, чынаяк). -Мә, (1-10) кашык(тәлинкә, чынаяк). -Мә, кызыл (сары, яшел, зәңгәр). чынаяк (тәлинкә, чынаяк).	Аудиоязма №30-37 Дәфтәрдә эш №9, 10 Сюжет: 1. “Өч аю” 2. “Чисталыкта - матурлык”
КИЕМНӘР - 8 СӘГАТЬ		
күлмәк чалбар ки	яшел (кызыл, сары, зәңгәр) күлмәк (чалбар). чиста күлмәк (чалбар). матур күлмәк (чалбар). күлмәк (чалбар) юк. -Оля, күлмәк (чалбар) бир. -Нинди күлмәк (чалбар)? -Сары (кызыл, яшел, зәңгәр) күлмәк (чалбар). -Ничә күлмәк (чалбар)? -Бер (1-10) күлмәк (чалбар). -Курчак, чалбар (күлмәк) ки (сал).	Аудиоязма №38-43 Дәфтәрдә эш №11, 12 Сюжет: 1.“Киемнәр кибетендә” 2.“Шаян уенчыклар”

  сал йокла	-Оля, чалбар (күлмәк) бир. -Мә, чалбар (күлмәк). -Рәхмәт. Курчак, мә, чалбар (күлмәк) ки (сал). -Курчак, йокла.	
ШӘХСИ ГИГИЕНА – 3 СӘГАТЬ		
бит кул хәерле көн	-Хәерле көн. -Мә су, бит (кул) ю. -Бит (кул) чиста. -Бит (кул) чиста. -Әйе, бит (кул) чиста.	Аудиоязма № 43, 44-48 Эш дәфтәре №13, 14 Сюжет: 1.“Ни өчен киемнәр югалган?”
ӨЙ ҖИҺАЗЛАРЫ – 3 СӘГАТЬ		
өстәл урындык карават	-Зур (кечкенә) урындык (өстәл, карават). -Зур аю, мә зур карават (өстәл, урындык). -Кечкенә аю, мә кечкенә карават (өстәл, урындык). -Нәрсә кирәк? -Карават (өстәл, урындык) кирәк. -Нинди карават? -Зур (кечкенә, сары, яшел, зәңгәр) карават. -Мә, зур карават. -Рәхмәт.	Аудиоязма № 49 Эш дәфтәре №15 Сюжет: 1.“Маша һәм өч аю”
БӘЙРӘМ “ТУГАН КӨН” – 7 СӘГАТЬ		
яратам	-Мин алма (ипи, сөт, чәй, ботка, аш, кыяр, кәбестә, бәрәңге, кишер) яратам. -Мин Коля(ны) (Оля(ны) яратам.	Аудиоязма №50-60 Эш дәфтәре №16-19

бар	-Мин курчак(ны) (аю(ны), песи(не), эт(не), куян(ны) яратам. -Нәрсә бар? -Туп (курчак) бар. -Нәрсә юк? -Туп (курчак) юк. "Бар", "Юк" сүзләрен кулланып "Гаилә", "Яшелчә" "Уенчыклар" темаларын кабатлау. Диалогларны кабатлау. "Кибетле" уеннары.	Сюжет: 1. "Туган көн" 2. "Кем нәрсә ярата?"
ЙОМГАКЛАУ - 7 СӘГАТЬ		
	Ел дәвамында өйрәнелгән сүзләр, сөйләм үрнәге кулланыла. "Гаилә", "Яшелчә", "Уенчыклар" темаларын кабатлау. "Кибетле" уеннары.	Аудиоязма №61-63 Сюжет: 1."Сабантуй бәйрәме"

Мәктәпкә әзерлек төркеме (6-7 яшь) «Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар» проекты

Белем бирү эшчәнлегенең бурычлары

1. Ашамлыклар, кыргый хайваннар, кошлар, мәктәп темасына кергән сүзләр хисабына баланың сөйләмен баету, тулыландыру.
2. Сөйләмне аралашу чарасы буларак камилләштерү, файдалана белү күнекмәләренә өйрәтү.
3. Диалогик һәм монологик сөйләмне үстерү.
4. Мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белергә күнектерү.

Белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге

Лексик минимум – якынча 60 сүз.

“Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар” проекты темалары (“Гаилә”, “Ашамлыклар”, “Уенчыклар”, “Саннар” , “Яшелчәләр”, “Савыт-саба”, “Киемнәр”, “Шәхси гигиена”, “Өй җиһазлары”, “Бәйрәмнәр”, “Танышу”, “Тату гаилә”, “Дусларны сыйлыйбыз”, “Кунак килде”, “Кафега барабыз”, “Күңелле уеннар”, “Без циркта”, “Безнең дуслар”, “Чана шуабыз”, “Без биибез”, “Күңелле сәяхәт”, “Мәктәп”, “Без әкият ятатабыз”) буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (танып – белү, уен, аралашу, музыка, хезмәт, хәрәкәт) ишетеп аңлап куллана белергә өйрәтү, сөйләм күнекмәләрен булдыру.

Яңа сүзләр хисабына баланың сөйләмен баету, тулыландыру: *син кем, хәерле көн, тычкан, бу кем, бу нәрсә, нишли, йоклый, утыра, ашый, эчә, нишлисең, ашыйм, эчәм, уйный, уйныйм, утырам, барам, кая барасың, син нишлисең, сикер-сикерәм, сикерә, йөгерә, төлке, йөгер-йөгерәм, чәк-чәк, өчпочмак, яшь, бүре, керпе, тавык, әтәч, үрдәк, чана, шуа, шуам, бие, бии, биим, ак, кара, җырла-җырлыйм, зур рәхмәт, китап укый, рәсем ясыйм, укыйм, дәфтәр.*

Бу кем? Бу нәрсә? Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Нишли? Син нишлисең? Кая барасың? соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белергә өйрәтү.

Алган белемнәрен, сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә камилләштерү. Монологик сөйләмне үстерү.

МӘКТӘПКӘ ӘЗЕРЛЕК ТӨРКЕМЕ «БЕЗ ИНДЕ ХӘЗЕР ЗУРЛАР – МӘКТӘПКӘ ИЛТӘ ЮЛЛАР» ПРОЕКТЫ БУЕНЧА ТЕМАТИК ПЛАН

АКТИВ СҮЗЛӘР	СӨЙЛӘМ ҮРНӘГЕ	АУДИОЯЗМА ЭШ ДӘФТӘРЕ АНИМАЦИОН СЮЖЕТ

син кем		Аудиоязма №1 - 2
хәерле көн	-Хәерле көн, Оля (Коля).	Аудиоязма №3 - 5
	-Хәерле көн, әни (әти, бабай, әби).	Дәфтәрдә эш №1
		Сюжет: “Мияу адашкан”
		Аудиоязма №6
тычкан		Дәфтәрдә эш №2
		Аудиоязма №7 - 8
бу кем?		Дәфтәрдә эш №3
		Сюжет:”Аю баласы дөнья белән таныша”
		Аудиоязма №9 - 10
		Дәфтәрдә эш №4
бу нәрсә?	-Песи нишли?	
	-Песи йоклый.	Аудиоязма №11
нишли?	-Әни нишли?	
йоклый	-Әни утыра.	Сюжет: “Батыр Мияу һәм куркак Куянкай”
утыра		
		Аудиоязма №12
		Дәфтәрдә эш №5
ашый	-Коля нишли?	
эчә	-Коля ашый (эчә).	Аудиоязма №13 - 14
нишлисең?	-Мияу, нишлисең?	

ашыйм	-Ашыйм.	
эчәм	-Акбай, нишлисең?	Мультфильм:
	-Эчәм.	“Тату гаилә”
		Аудиоязма №15
уйный	-Оля (Коля), нишлисең?	
уйныйм	-Уйныйм.	Аудиоязма №16 - 18
утырам		Мультфильм: “Юмарт аю”
		Аудиоязма №19
		Аудиоязма №20
барам	-Кая барасың?	Дәфәрдә эш №6
кая барасың?	-Кафега барам.	
син нишлисең?	-Син нишлисең?	
	-Мин бәрәңге ашыйм (чәй эчәм, уйныйм, барам, утырам, йоклый)	Мультфильм: “Кафега барабыз”
		Дәфтәрдә эш №7
сикер-сикерәм	Туп, туп	
	Матур туп.	Аудиоязма №21-23
	Сикер-сикер,	
	Матур туп.	
сикерә	Куян сикерә (йөгерә).	Мультфильм:
йөгерә	Туп сикерә.	“Урманда күңелле уеннар”
төлке	Песи сикерә (йөгерә).	

	Төлке сикерә (йөгерә).	Аудиоязма №24 Дәфтәрдә эш №8 Аудиоязма №25-28
йөгер-йөгерәм	-Йөгер! Син нишлисең? -Мин йөгерәм.	Мультфильм: “Көчлеләр, кыюлар, җитезләр”
чәк-чәк өчпочмак	-Мин чәк-чәк ашыйм. -Мин өчпочмак ашыйм.	Аудиоязма №29-30 Дәфтәрдә эш №9
яшь	-Сиңа ничә яшь? -6 яшь.	Сюжет: “Җәнлекләр спорт бәйрәмендә” Аудиоязма №31-32
бүре керпе	-Мин бүре. Мин зур, матур, чиста.	Аудиоязма №33-34 Дәфтәрдә эш №10
тавык әтәч	Әтәч зур, матур Тавык кечкенә, матур	Сюжет: “Циркта”
үрдәк	-Син кем? -Мин үрдәк.	Аудиоязма №35 - 36 Дәфтәрдә эш №11 Аудиоязма №37 - 38 Дәфтәрдә эш №12

чана шуа шуам	Куян чана шуа. Мин чана шуам.	Сюжет: “Шаян кошлар” Аудиоязма №39 - 40
		Аудиоязма №41 Дәфтәрдә эш №13
бие бии биим	-Аю, әйдә, бие!	Сюжет: “Урманда зур концерт” Аудиоязма №42 - 44 Дәфтәрдә эш №14
		Аудиоязма №45 - 46
ак кара	-Оля кызыл шар ярата? -Юк. -Оля яшел шар ярата? -Әйе, мин яшел шар яратам.	Сюжет: “Акбай туган көнгә барырга җыена” Аудиоязма №47 Дәфтәрдә эш №15
җырла-җырлыйм	-Син нишлисең? -Мин җырлыйм.	Аудиоязма №45, 48 – 49
	җырлыйбыз	Сюжет: “Мияуның туган көне” Аудиоязма №50

	зур рәхмәт	Дәфтәрдә эш №16
зур рәхмәт		Аудиоязма №51 - 53
		Дәфтәрдә эш №17
		Сюжет:
		“Урман китапханәсендә”
китап укый	Кыз китап укый.	
		Аудиоязма №54 - 60
		Дәфтәрдә эш №18
рәсем ясыйм	рәсем ясыйм-алма ясыйм	
	мәктәп	Сюжет “Уйный-уйный укыйбыз”
		Аудиоязма №61-63
		Дәфтәрдә эш №19
укыйм	-Кем укый.	Сюжет: “Урман мәктәбендә”
	-Мин укыйм.	
		Аудиоязма №64
		Сюжет: “Теремкәй”
		Аудиоязма №65-66
дәфтәр	бик тәмле	
		Сюжет: “Кем нәрсә ярата?”
	Терем-терем, теремкәй,	Аудиоязма №67 - 71
	Зур түгел, кечкенә.	Дәфтәрдә эш №20
	Теремкәйдә тычкан яши.	

	Теремкәйдә куян яши. Теремкәйдә бүре яши. Теремкәйдә төлке яши. Теремкәйдә аю яши. Алар бик дус. -Кәҗә кая? -Әнә, кәҗә кәбестә ашый. Кәҗә кәбестә ярата. -Мин ипи яратам. Песи, син нәрсә яратасың? -Мин сөт яратам. Сөт тәмле. -Мә, кәҗә, ботка аша. -Юк, кәбестә яратам. Кәбестә тәмле.	

2.2. «Туган телдә сөйләшәбез» проекты
«Туган телдә сөйләшәбез». Комплекслы тематик план (2-3 яшь)

№	Проект темалары	Эшчәнлек төрләре	Эшчәнлек саны
1.	**Танышу**	Танышу	6
2.	**Безнең балалар бакчасы**	Аю белән куян кунакка килгән Куянга өй төзибез Курчагым “Үчтеки, үчтеки” такмагын уку Курчакның туган көне Карусельгә сәяхәт Минем матур тубым Әминә Бикчәнтәеваның “Туп-туп, тубыбыз” шигырен уку	1 1 1 1 1 1 1 1 1

		Уенчыклар кибетендә	1 1
3.	**Көз**	Көз җитте Көзге яфраклар ”Безнең Алсу “ сериясеннән рәсем карау Яшелчәләр Куян кунакка килгән “Шалкан” әкияте Җиләк-җимешләр Әбидә кунакта Яшелчә бакчасында	1 1 1 1 1 1 1 1 1
4.	**Мин - дөньяның бер кешесе**	Минем исемем бар Бу — мин Мин –дөньяның бер кешесе	1 1 1
5.	**Гаилә**	Минем гаиләм Безнең гаилә Әйдәгез дуслашыйк Бу өйдә кем яши? Без чәбәкәй итәбез Уйнарга яратабыз “Гаилә” рәсемен карау Шәйхи Маннурның “Яратам” шигырен уку Әйдәгез уйныйбыз	1 1 1 1 1 1 1 1 1
6.	**Кыш**	Ап-ак кар ява Алсу урамга җыена Кар бабай ясау Кыш рәсемен карау Кар ява А.Алиш “Куян кызы”	1 1 1 1 1 1
7.	**Яңа ел бәйрәме**	Яшел чыршы Әминә Бикчәнтәеваның «Беренче адым» шигырен уку Чыршы бизибез Куян чыршы янында Купшы чыршы Без музыка залында	1 1 1 1 1 1

8.	**Минем әйләнә - тирәм**	Яраткан уен бүлмәбез	1
		Алсу бүлмәсе	1
		Безнең урам	1
		Безнең апа	1
		Алсу авырган	1
		Алсуда кунакта	1
		Безнең йортта нәрсәләр яши?	1
		Йорт кошлары	1
		Хайваннарны чакыру	1
		Маэмаем	1
		М.Җәлилнең “Әтәч” шигырен уку	1
		Гав исемле мәче баласы	1
		Габдулла Тукай “Гали белән Кәҗә”	1
		“Чуар тавык” әкияте	1
		Әкияттә кунакта	1
9.	**Әтиләр-бабайлар**	Зур гаилә	1
		Безнең әтиләр һәм абыйлар	1
		Бабайга кунакка барабыз	1
		Машина	1
		Самолет	1
		Булатның машинасына гараж ясау	1
10.	**Әниләр-әбиләр**	Кибеткә бару	1
		Әбидә кунакта	1
		Безнең әниләр	1
		Алсуны табибка алып барабыз	1
		Табибка барабыз	1
		Курчакны йоклату	1
11.	**Халык иҗаты**	Хайваннарны чакыру	1
		”Йомры икмәк” рус халык әкиятен уку	1
		“Шалкан” әкиятен уку	1
		Авылда	1
		“Теремкәй” рус халык әкиятен уку	1
		Өч аю	1
12.	**Яз**	Урамда яз	1
		Яз җитә	1
		Яз	1

		Җәнлекләр урманда яшиләр Язгы урманда Күңелле ял итәбез Агачлар Каргалар Без уйныйбыз Яз килде Аваз культурасы А, Ә авазы Акбай һәм Мияу маҗаралары	1 1 1 1 1 1 1 1 1
13.	**Җәй**	Бүлмә гөлләре Бүлмә гөлләре Мультфильмда кунакта Саф һавада Чәчәкләр Балалар бакчасы ишегалдында Экология сукмагы буенча сәяхәт Су белән уен Мультфильмда кунакта Әнәс Кариның “Чебиләр” шигырен уку Рәхмәт, җәй! Уеннар	1 1 1 1 1 1 1 1 1 1 1 1
			105 сәгать

«Туган телдә сөйләшәбез» Комплекслы тематик план. Икенче кечкенәләр төркеме (3-4 яшь)

№	Проект темалары	Эшчәнлек төрләре	Эшчәнлек саны
1.	**Исәнме, балалар бакчасы**	Танышу Өйдә кем яши? Мин малай, мин кыз Мияу белән танышу Әйдәгез танышыйк Әйдә дуслашыйк	1 1 1 1 1 1
2.	**Уенчыклар**	Минем яраткан уенчыкларым	1

		Минем яраткан уенчыкларым Карусельгә сәяхәт Без уйнарга яратабыз Йомшак уенчык карау Туп Туган көн Мияу кунакка килгән Уенчыклар кибете	1 1 1 1 1 1 1 1
3.	**Көз**	Алтын көз Көз килде Аваз культурасы, Ө авазы Куян үстергән кишер һәм помидор Яшелчә бакчасында “Шалкан” әкияте Җиләк-җимеш бакчасында Бакчада алмалар өлгерде Уйный-уйный саныйбыз	1 1 1 1 1 1 1 1 1
4.	**Гаилә**	Өйдә кем яши? Безнең гаилә Качышлы уйныйбыз Тату гаилә Минем дуслар Әйдәгез дуслашыйк Минем туганнарым Безнең гаилә Әби күчтәнәче Дустыңны сыйла Сөт,чәй Кунакка барабыз	1 1 1 1 1 1 1 1 1 1 1 1
5.	**Кыш**	Кар ява Алсуны урамга киендерәбез	1 1

		А.Алиш “Куян кызы” “Чанада шуабыз” рәсемен карау Кышкы уеннар “Куяннар”уенын өйрәнү	1 1 1 1
6.	**Яңа ел бәйрәме**	Тиздән чыршы бәйрәме Б.Рәхмәтнең “Кыш бабай” шигырен ятлау Уйныйбыз да, җырлыйбыз да Без бәйрәмгә әзерләнәбез Бәйрәм концерты Яңа ел бәйрәме	1 1 1 1 1 1
7.	**Минем йортым, минем шәһәрем**	Минем шәһәрем Мин “КамАЗ” оныгы “Әлли-бәлли итәргә...”бишек җыры Безнең урам Алсуның яңа өе Алсуда кунакта	1 1 1 1 1 1
8.	**Безнең авылда**	Безнең авылда Зурлар һәм кечкенәләр “Кем нәрсә ярата?”татар халык әкиятен сөйләү “Песи һәм песи балалары”рәсемен карау Җ.Тәрҗемановның”Үзен бик чиста йөртә”шигырен уку “Кем МИЯУ дип әйтте?” Йорт кошлары Р.Батулланың “Елак этәч”әсәрен уку Без уйныйбыз	1 1 1 1 1 1 1 1 1
9.	**Ватанны саклаучылар көне**	Зур гаилә Безнең әтиләр һәм абыйлар Бабайга кунакка барабыз Ватанны саклаучылар көне Очучылар	1 1 1 1 1

		З.Туфайлованың “Шофёр булам”шигырен уку	1
10.	**8нче март**	Минем әнием Кояш гомере телим мин, әнием, сиңа! Без әнигә булышабыз Әбигә кунакка барабыз Мин әнинең ярдәмчесе Азат кунак чакыра	1 1 1 1 1 1
11.	**Кыргый хайваннар**	Урманда Аю белән куян “Өч аю”әкияте	1 1 1
12.	**Әкияттә кунакта**	“Теремкәй” рус халык әкиятен сөйләү Кыргый хайваннар “Төлке, куян һәм әтәч”әкиятен сәхнәләштерү	1 1 1 1
13.	**Яз**	Урамда яз Яз җитте Яз җыры “Кояш чык,чык,...” Язгы күренешләр Ак аю кунакка килгән Кошлар Х.Вахитның “Уңган сыерчык”шигырен уку Без уйныйбыз	1 1 1 1 1 1 1 1 1
14.	**Бәйрәмнәр**	Бәйрәмгә барабыз “Балалар бакчасында бәйрәм” дигән рәсем карау “Урманда зур концерт” - анимацион сюжет карау	1 1 1
15.	**Җәй**	Автобуста сәяхәт Ж.Тәрҗемановның “Кикрикүк” шигырен уку Мультфильмда кунакта М.Мазуновның “Кәҗә”шигырен уку	1 1 1 1

		“Кәҗә һәм кәҗә бәтиләре” рәсемен карау Чәчәкләр-тормыш яме Матур җәй, кил безгә Мин җәйне яратам “Карга” эндәшен уку Саф һавада Экология сукмагы буенча сәяхәт Без уйныйбыз	1 1 1 1 1 1 1 1
			105сәгать

2.3. Эш төрләре һәм формалары

Программа бурычларын үтәүдә эш формаларының, практик гамәли алымнарның, чараларның әһәмияте зур. Төп эш төрләре булып түбәндәгеләр тора:

Предметлар белән эш: тасвирлау, уенчык белән диалог төзү, уен һәм әкиятләрдә катнашу.

1. Рәсемнәр белән эш: тасвирлау, үстерешле диалог.
2. Сюжетлы-рольле уеннар.
3. Әйлән-бәйлән, җырлы-биюле уеннар өйрәнү (аудиоязмага таянып).
4. Театральләштерү, сәхнәләштерү: бармак театры, битлекләр, костюмнар, театр күрсәтү (әти-әниләргә, башка төркем балаларына).
5. Хәрәкәтле уеннар: туп белән уеннар, «Командир» уены, әйлән-бәйлән уены, зарядка уеннары.
6. Иҗади һәм ситуатив уеннар: рольле уеннар, интервью, ситуатив күнегүләр.
7. Ситуатив, логик күнегүләрне ишетеп, аңлап эшләү.
8. Үстерелешле диалоглар (өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән үзара аралашу).
9. Аудиоязмалар тыңлау, кушылып әйтү, җырлау, кабатлау, ишеткән сүзне рәсемдә табып күрсәтү.
10. Анимацион сюжетлар, мультфильмнар карау.
11. Интерактив уеннар.

Укыту-методик комплектының эчтәлеге

Һәр проект түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) тематик план;
2) эшчәнлек конспектлары;

3) балалар һәм эти-әниләр өчен эш дәфтәрләре;
4) аудиоязмалар;
5) анимацион күренешләр;
6) күрсәтмә, таратма материаллар;
7) диагностик материаллар.

Программа өч проектны, аларның төп максатларын һәм бурычла¬рын үз эченә ала.

2.4. Коррекцион һәм инклюзив эш *(Кушымта №1)*

Коррекцион һәм инклюзив педагогикага багышланган бүлектә түбәндәге атамалар һәм төшенчәләр кулланыла. Инклюзив белем бирү — махсус белем бирү ихтыяҗларының һәм индивидуаль мөмкинлекләрнең төрлелеген исәпкә алып, барлык балаларның белем алуы өчен тигез мөмкинлекләр тәэмин итү. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле (СМЧ) укучы — физик һәм (яки) психологик үсешендә психологик-медицина-педагогик комиссия тарафыннан расланган һәм махсус шартлар тудырылмыйча белем алуга тоткарлык тудыручы тайпылышлары булган физик зат. Җайлаштырылган (адаптацияләштерелгән) белем бирү программасы — сәламәтлек мөмкинлекләре чикле затларны психофизик үсеш үзенчәлекләрен, индивидуаль мөмкинлекләрен исәпкә алып укыту өчен җайлаштырылган һәм кирәк очракта күрсәтелгән затларның үсеш тайпы- лышларын коррекцияләүне һәм социаль адаптацияләүне тәэмин итүче белем бирү программасы. СМЧ затлар төркеменә: саңгыраулар, начар ишетүчеләр, башта ишетеп, соңрак ишетми башлаганнар, сукырлар, начар күрүчеләр, сөйләме нык бозылганнар, терәк-хәрәкәт аппараты (ТХА) тайпылышы булганнар, психик үсеш тоткарлыгы булганнар, интеллектуаль үсеш тоткарлыгы булганнар, аутистик спектры бозылганнар (АСБ), катлаулы дефектлары булганнар һ.б. керә. Катнаш юнәлештәге төркемнәрдә сәламәт балаларга һәм СМЧ балаларга белем бирү мәктәпкәчә оешманың белем бирү программасы буенча, тәрбияләнүчеләрнең психофизик үсеш үзенчәлекләрен һәм мөмкинлекләрен исәпкә алып, берләштереп алып барыла.

2.5. Татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү

Уку елы ахырында уртанчылар, уку елы башында зурлар төркеме балаларының “Минем өем” проекты буенча татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү.

№	Баланың исеме, фамилиясе	Биремнәр					Нәтиҗә	
		1	2	3	4	5	баллар	дәрәҗә
		“Минем өем” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. (Өйрәнгән темалар буенча дүрт – биш рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә кушыла)	Ягымлы сүзләр куллану (“исәнме”, “сау бул”, “рәхмәт”)	Боерыкны аңлап үтәү һәм куллана белү (кил, утыр, сикер, ю, аша, эч)	Тирә - юньдәге предметларның сыйфатын, күләмен белдерә торган сүзләрне аңлап сөйләмдә куллану.	Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сарап алу, тәкъдим итү, инкарь иү, раслау)		
1.	Коля							
2.	Оля							

Нәтиҗәләрне билгеләү	
Югары дәрәҗә 2,7 дән 3 кә кадәр	Бала сөйләмдә актив, сорауларга җавап бирә, яхшы аралаша.
Уртача дәрәҗә 2 дән 2,6 га кадәр	Сүз байлыгы бар, аралашуда бик үк актив түгел.
Уртачадан түбән дәрәҗә 1 дән 2 гә кадәр	Аңлый, русча җавап бирә.

Балаларның татар телендә аралаша белү дәрәҗәсен тикшергәндә кулланырга мөмкин булган биремнәр.

1. “**Минем өем” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану.**

1. ***Дидактик уен. "Бу кем?"*** *(I вариант)*

(Лексика: әти, әни, кыз, малай, әби, бабай)

Уен эчтәлеге: Өй рәсеме. Өй тирәсендә гаилә әгъзалары рәсемнәре (комплекттагы күрсәтмә рәсемнәр). Тәрбияче рәсемнәргә күрсәтеп сорый: Бу кем? ("Әни"...).

2. ***Дидиктик уен "Кем юк?"*** *(II вариант)*

(Лексика шул ук).Уен шул ук рәсемнәр кулланып үткәрелә. Тәрбияче бер рәсемне алып куя. Баладан сорый: "Кем юк?" ("Әби"...)

Уенны интерактив тактада да, бала белән бала арасында диалог формасында да үткәрергә була)

3. ***Дидактик уен "Кәрзиндә нәрсә бар?"***

(Лексика: ипи, алма, сөт, чәй)

Уен эчтәлеге: Мияу кәрзин белән ашамлыклар алып килгән. Мияу ашамлык муляжларына күрсәтә, исемен сорый: "Бу нәрсә?" ("Алма"...)

4. ***Дидактик уен "Нәрсә юк?"***

Мияу бер ашамлык муляжын яшереп куя: "Нәрсә юк?". Бала нәрсә юклыгын әйтергә тиеш. ("Алма"...) Уенны рәсемнәр кулланып та үткәреп була.

5. ***Дидактик уен "Мин әйтәм, син күрсәт һәм әйт"***

(Лексика: әти, әни, кыз, малай, әби, бабай; куян, аю, туп, машина, курчак, эт, песи, ипи, алма, сөт, чәй).

Уен эчтәлеге: Балага уенчык яисә уенчык рәсемнәре бирелә. Бала, тәрбияче әйткән уенчыкны яисә уенчык рәсемен табып күсәтергә һәм исемен кабатлап әйтергә тиеш.

6. ***Дидактик уен "Исемен әйтсәң бирәм"***

(Лексика: куян, аю, туп, машина, курчак, эт, песи)

Уен эчтәлеге: Тәрбияче өстәлендә уенчыклар яисә рәсемнәр. Тәрбияче балага уенчыкны(рәсемне) күрсәтә, сорый: "Бу нәрсә?"- "Алма"... ; "Бу кем?"-"Әти"... Бала уенчык исемен дөрес әйтсә аңа уенчыклар, яисә таратма рәсемнәр бирелә.

<u>7. Дидактик уен "Серле янчык"</u>

(Лексика: куян, аю, туп, машина, курчак, эт, песи)

Уен эчтәлеге: Балага уенчыклар күрсәтелә, исемнәрен әйтеп янчыкка салына. Бала янчыктагы уенчыкны капшап исемен әйтә, алып күрсәтә.

<u>8. Дидактик уен "Әйе-юк"</u>

Сүзнең дөрес үзләштерелүен тикшерү йөзеннән (аңлап яки аңламыйча әйтү) төрле вариантта сораулар бирелә: "Бу нәрсә?" - "Аю"...; "Бу аю?" - "Әйе, аю"...; "Бу куян?" - "Юк, песи"...

<u>Югары балл (2.7-3)</u> — сүз байлыгы җитәрлек, уенчык, әйберләрне үзлектән, аңлап дөрес күрсәтә, исемнәрен әйтә.

<u>Уртача балл (2-2,6)</u> - сүз байлыгы бар, кайбер сорауларга тәрбияче ярдәмендә җавап бирә.

<u>Уртачадан түбән балл (1-2)</u> - аңлый, русча җавап бирә.

2. Ягымлы сүзләр куллану (“исәнме”, “сау бул”, “рәхмәт”).

Ситуатив күнегүләр:

а) Ситуатив күнегү “Куян аюга кунакка килә”. Ул ишектән кергәндә аюга нәрсә әйтә? (Ничек исәнләшә?), "Исәнме аю".

б) Ситуатив күнегү “Куян аюда кунакта булды”. Ишектән чыгып киткәндә куян аю белән ничек саубуллаша? (Нәрсә әйтә?) "Сау бул, аю".

в) Уен ситуациясе "Кунак сыйлау". Акбайда (Мияуда) кунакта.

Тәрбияче Акбай (Мияу) ролендә. Ул баланы, ашамлык, җиләк-җимеш (алма, груша, банан һ.б.) муляжлары белән "сыйлый". Тәрбияче баланың "рәхмәт" әйтә белүен билгели.

г) Уен ситуациясе "Дустыңны сыйла". Балаларны парлаштырып бер-берсен сыйларга тәкъдим итү. Рәхмәт әйтә белүләрен билгеләү.

д) Ситуатив күнегү "Акбайга ("Мияуга", "Курчакка", "Дустына") уенчык бүләк ит".

<u>Югары балл (2,7-3)</u> - бала ситуацияләрдә ягымлы сүзләрне урынлы куллана.

<u>Уртача балл (2-2.6)</u> - тәрбияче ярдәмендә җавап бирә.

<u>Уртачадан түбән (1-2)</u> - аңлый, сорауга җавапны русча әйтә.

3. Боерыкны аңлап үтәү һәм куллана белү (кил, утыр, сикер, ю, аша, эч).

1. Сүзле уен "Мин әйтәм - син эшлә" ("Командир").

2. Сүзле уен "Шаян уенчыклар" (Уен баланың боерыкларны аңлы рәвештә үтәвен тикшерү өчен бирелә. Уенның эчтәлеге: Тәрбияче уенчыкка боерык бирә, мәсәлән: Утыр! Ә уенчык “ашый” башлый. Бала боерыкны дөрес итеп үтәп күрсәтә).

<u>Югары дәрәҗә (2,7-3)</u> - бала боерыкны аңлап, дөрес үти.

Уртача дәрәҗә (2-2,6) - ялгыша.

<u>Уртачадан түбән дәрәҗә (1-2)</u> - татарча аңламый, боерыкларны үтәми.

4.Тирә-юньдәге предметларның сыйфат билгеләрен, күләмен белдерә торган сүзләрне аңлап сөйләмдә куллану.

1. ***<u>Дидактик уен "Уенчык нинди?" (зур, кечкенә, чиста, пычрак, әйбәт, матур).</u>***

   Уен эчтәлеге: зур-кечкенә уенчыклар күрсәтелә. Тәрбияченең "Нинди?" соравына бала уенчыкның исемен сыйфат билгесе белән әйтергә тиеш.

   -Нинди курчак? - Зур (кечкенә, чиста, пычрак, әйбәт, матур) курчак.

   Эш дәфтәрендәге 11 нче биремне кулланып була.

2. ***<u>Дидактик уен "Тап, күрсәт һәм әйт" (чиста, пычрак).</u>***

   Комплекттагы күрсәтмә рәсемнәр кулланып үткәрелә. Тәрбияче әйткән рәсемне бала табып күрсәтә, әйтә.("Чиста туп", "Пычрак аю"...).

   Эш дәфтәрендәге 13 нче биремне кулланып була.

3. ***<u>Дидактик уен "Курчакка бүләк".</u>***

   Тәрбияче зур курчакка- зур туп, кечкенә курчакка- кечкенә туп бүләк итәргә куша. “ Мә, зур туп ", “Мә, кечкенә туп".

4. ***<u>Дидактик уен "Дөрес сана".</u>***

   Санау күнекмәләрен билгеләү (1-5 кадәр). Тәрбияче уенчыклар, муляжлар санарга тәкъдим итә. Төркемдәге балаларны да санарга була. "Ничә малай?", "Ничә кыз?".

5. ***<u>Дидактик уен "Ничә?".</u>***

   Санау күнекмәләрен тикшерү өчен шулай ук, укыту методик комплектындагы күрсәтмә рәсемнәрне дә кулланып була.

   - Ничә туп? - Биш туп.

   <u>Югары дәрәҗә (2,7-3)</u> - әйберләрнең сыйфат билгеләрен, күләмен исем белән кушып дөрес әйтә.

   <u>Уртача дәрәҗә (2-2.6)</u> - 1-2 билгесен әйтә.

   <u>Уртачадан түбән дәрәҗә (1-2)</u> - әйберләрнең билгеләрен, күләмен рус телендә әйтә.

5. Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сарап алу, тәкъдим итү, инкарь итү, раслау).

1. Уен ситуациясе "Әйдәгез танышабыз".

"Син кем?" соравына аңлап җавап бирүе билгеләнә. К нам пришла новая кукла, она хочет с вами познакомиться: -Исәнмесез. Мин Алсу. Син кем? (Мин Оля (Коля). -Мин Алсу, мин кыз. Син кыз? (Юк, мин малай (әйе, мин кыз).

2. Уен ситуациясе "Кунак каршылыйбыз ".

а) Тәрбияче: К нам идут гости.

Спроси. "Кто там?". "Кем анда?" - Мин әби (бабай).

"Позови бабушку (дедушку)". - Әби (бабай) кил монда.

"Поздоровайся с бабушкой (дедушкой)" - Исәнме, әби (бабай).

"Спроси у бабушки (дедушки) как дела?" - Әби (бабай) хәлләр ничек? - Әйбәт, рәхмәт.

"Предложи бабушке (дедушке) сесть". - Әби (бабай) утыр.

"Предложи бабушке (дедушке) пить чай" - Мә, чәй, эч.

Скажи: "До свидания!" Сау бул, әби! (бабай).

б) Балага "кунак" белән исәнләшергә, хәлен сорарга, чакырып утыртырга, сыйларга ("аша,эч") һәм саубуллашырга тәкъдим ителә.

Эш дәфтәрендәге 3 нче биремне кулланып була**.**

1. Уен ситуациясе "Кунакларны сыйла".

Угости Акбай хлебом, Мияу молоком.

-Мә, Акбай ипи, аша. - Рәхмәт.

-Мә, Мияу сөт, эч. - Рәхмәт.

Эш дәфтәрендәге 16 нчы биремне кулланып була**.**

2. Уен ситуациясе "Бер - берeңне сыйла ".

(Ашамлык муляжлары кулланып)

"Угости яблоком".

- Мә, алма, аша. - Рәхмәт.

"Спроси, яблоко вкусное?"

- Алма тәмле? - Әйе, тәмле.

Эш дәфтәрендәге 6 нчы биремне кулланып була.

3. ***Уен ситуациясе "Уенчыклар илендә"***

1 . Ты пришел в магазин игрушек. Попроси игрушку, которая тебе нравится.

-Куян бир (әле).- Рәхмәт.

2. Предложи поиграть с игрушкой.

- Мә, туп, уйна. - Рәхмәт.

3. Позови друга, предложи помыть игрушку.

-Коля, кил монда. - Мә, туп, ю.

4. Поменяйтесь игрушками. Попроси у друга игрушку, предложи ему свою .

- Коля, туп бир - Мә, туп.

- Рәхмәт.

Югары дәрәҗә (2,7-3) - аралаша, сөйләм күнекмәләрен актив куллана.

Уртача дәрәҗә (2-2,6) - тәрбияче ярдәмендә аралаша.

Уртачадан түбән дәрәҗә (1-2) - аңлый, русча җавап бирә.

Уку елы ахырында зурлар, уку елы башында мәктәпкә әзерлек төркеме балаларының

“Уйный-уйный үсәбез” проекты буенча татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү.

№	Баланың исеме, фамилиясе	Биремнәр					Нәтиҗә	
		1	**2**	**3**	**4**	**5**	**баллар**	**дәрәҗә**
		“Уйный – уйный үсәбез” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. (Өйрәнгән темалар буенча биш – алты рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә кушыла)	Ягымлы сүзләр куллану (“исәнме”, “сау бул”, “рәхмәт”. “исәнмесез”, “ сау булыгыз”)	Боерыкны бирә белү (кил, утыр, сикер, уйна, ю, аша, эч, ки, сал)	Уен ситуацияләрендә үзлектән сорау бирә белү (Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә?)	Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкарь итү, раслау)		
1.	Коля							
2.	Оля...							

Нәтиҗәләрне билгеләү	
Югары дәрәҗә 2,7 дән 3 кә кадәр	Бала сөйләмдә актив, үзлектән сорау бирә, яхшы аралаша.
Уртача дәрәҗә 2 дән 2,6 га кадәр	Сүз байлыгы бар, тәрбияче ярдәмендә аралаша.
Уртачадан түбән дәрәҗә 1 дән 2 гә кадәр	Аңлый, русча җавап бирә.

1.“Уйный – уйный үсәбез” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану.
(Өйрәнгән темалар буенча биш – алты рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә кушыла)

1. ***Дидактик уен “Бу нәрсә?”***
   (Лексика: аш, ботка, сөт, кашык, тәлинкә, чынаяк).
   Уен эчтәлеге: Тәрбияче рәсемнәргә күрсәтеп сорый:
- Бу нәрсә? (“Аш”...)
2. ***Дидактик уен “Кәрзиндә нәрсә бар?”***
   (Лексика: кишер, суган, бәрәңге, кыяр, кәбестә, алма).
   Уен эчтәлеге: Куян кәрзин белән яшелчәләр һәм җиләк-җимеш алып килгән. Куян сорый: “Нәрсә бар?” (“Кәбестә”...)
3. ***Дидактик уен “Нәрсә юк?”.***
   (Лексика: кишер, суган, бәрәңге, кыяр, кәбестә, алма).
   Куян бер яшелчә муляжын яшереп куя: “Нәрсә юк?”. Бала нәрсә юклыгын әйтергә тиеш. Уенны рәсемнәр кулланып та үткәрергә була.
4. ***Дидактик уен “Дөресен әйт”.***
   (Лексика: күлмәк, чалбар, сарафан, өстәл, урындык, карават).
   Уен эчтәлеге: Балага рәсемнәр бирелә. Бала рәсемнәрнең исемен атый һәм күрсәтә.

Югары балл (2.7-3) — сүз байлыгы җитәрлек, яшелчәләр, савыт-сабалар, киемнәр, өй җиһазлары атамаларын аңлап дөрес күрсәтә, исемнәрен әйтә һәм куелган сорауларга җавап бирә.
Уртача балл (2-2,6) - сүз байлыгы бар, кайбер сорауларга тәрбияче ярдәмендә җавап бирә.
Уртачадан түбән балл (1-2) - аңлый, русча җавап бирә.

2. Ягымлы сүзләр куллану (“Исәнме”, “Сау бул”, “Рәхмәт”, “Исәнмесез”, “ Сау булыгыз”).

Ситуатив күнегүләр (уртанчылар төркемендәге ягымлы сүзләр бүлеген кара):

а) Поздоровайся с Акбаем.
б) Спроси как дела у Акбая.
в) Скажи спасибо Акбаю. Спроси как дела.
г) Попрощайся с Акбаем.

д) Поздоровайся с воспитателем, Мияу и Акбай.

е) Попрощайся с воспитателем, Мияу и Акбай.

Югары балл (2.7-3) — бала сөйләмдә ягымлы сүзләрне урынлы куллана.

Уртача балл (2-2,6) – уен ситуацияләрен тәрбияче ярдәмендә төзи.

Уртачадан түбән балл (1-2) – аңлый, җавап бирә алмый.

3. Боерыкны бирә белү (кил, утыр, сикер, уйна, ю, аша, эч, ки, сал).

Балаларның боерыкларны бирә белү күнекмәләрен тикшерү. Балалар бер-берсенә боерык бирәләр. Саша, аша! – Саша ашау хәрәкәтләре күрсәтә. Алга таба Саша үзе башка балага боерык бирә һәм шундый тәртиптә дәвам ителә.

(Лексика: кил, утыр, сикер, ю, аша, эч, уйна, ки, сал).

Югары балл (2,7-3) – 8-9 сүз.

Уртача балл (2-2.6) – 5-6 сүз.

Уртачадан түбән (1-2) – 1-2 сүз.

4. Уен ситуацияләрендә үзлектән сорау бирә белү. (Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә?).

1. Сюжетлы-рольле уен “Кибет”

Балаларга рус телендә кибет уены үткәрү аңлатыла һәм өч төп сорауны куя белүләрен максат итеп куясың. Уен яшелчә, киемнәр, савыт-саба, өй җиһазлары рәсемнәре кулланып үткәрелә.

(Лексика: Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә?).

2. Дидактик уен “Нинди?”.

Тикшерүдә сорауларны аерым кулланып та үткәрергә була.

Әйберләрне билгесен ачыклау өчен бирелә торган сорауга аңлап җавап бирү һәм ул сорауларны үзлектән куя белү.

(Лексика: нинди? кызыл, сары, яшел, зәңгәр).

3. *Дидактик уен “Ничә?”.*

Санау күнекмәләрен билгеләү (1- 10 кадәр).

*4. **Дидактик уен “Дөрес сана”.***

Тәрбияче уенчыклар, муляжлар, укыту методик комплектындагы күрсәтмә рәсемнәрне санарга тәкъдим итә. Балалар бер-берсенә сорау бирәләр һәм җавап бирәләр. Шулай ук, сорауны тәрбияче үзе дә бирә ала. *“Ничә...?”*.

Югары балл (2,7-3) – диалогта 3 сорауны да аңлап куллана.

Уртача балл (2-2.6) – диалогта 2 сорауны аңлап куллана**.**

Уртачадан түбән (1-2) – диалогта 1 сорауны аңлап куллана**.**

5. Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкарь итү, раслау).

1. ***Уен ситуациясе "Әйдәгез танышабыз".***

"Син кем?" соравына аңлап җавап бирүе билгеләнә.

К вам пришла новая кукла, она хочет с вами познакомиться:

- Исәнмесез. Мин Алсу. Син кем? (Мин Оля яки Коля).
- Мин Алсу, мин кыз. Син кыз? (Юк, мин малай).

2. ***Уен ситуациясе "Кунак каршылыйбыз".***

а)Тәрбияче:

- К нам идут гости. Спроси. "Кто там?". "Кем анда?"
- Мин Акбай.
- Позови Акбая.
- Акбай, кил монда.

б)У Акбая сегодня день рождение. Подари свою игрушку

- Акбай, мә кызыл туп.
- Рәхмәт.

в) Угости гостей супом или кашей.

- Мә, аш (ботка) (аша).

г)Что бы сьесть угощение попроси ложку.

- Кашык бир.
- Нинди кашык?
- Зур, матур, зәңгәр кашык.

- Рәхмәт.

3. ***<u>Уен ситуациясе “Кибеттә”.</u>***

   Бала белән бала аралашуы тикшерелә.

- Исәнме! Хәлләр ничек?
- Әйбәт, рәхмәт.
- Аю бир.
- Нинди аю?
- Зур аю, чиста аю, матур аю.
- Ничә?
- Ике аю.
- Мә, ике аю.
- Рәхмәт.
- Сау бул.

<u>Югары балл (2,7-3)</u> – бала сөйләмдә актив, үзлектән сорау бирә, яхшы аралаша.

<u>Уртача балл (2-2.6)</u> – сүз байлыгы бар, тәрбияче ярдәмендә аралаша.

<u>Уртачадан түбән (1-2)</u> – аңлый, русча җавап бирә.

Уку елы ахырында мәктәпкә әзерлек төркеме балаларының

“Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты буенча татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү.

№	Баланың исеме, фамилиясе	Биремнәр					Нәтиҗә	
		1	2	3	4	5	баллар	дәрәҗә
		“Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. (Өйрәнгән темалар буенча биш – алты рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә кушыла)	Ягымлы сүзләр куллану (“исәнме”, “исәнмесез”, “сау бул”, “сау булыгыз”, “рәхмәт”, “зур рәхмәт”, “хәерле көн”, “хәлләр ничек?”, “әйбәт”)	Боерыкны бирә белү (кил, утыр, сикер, уйна, ю, аша, эч, ки, сал, бие, җырла, йөгер, йокла)	Уен ситуацияләрендә үзлектән сорау куя белү. (Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Син кем? Бу кем? Бу нәрсә? Нишли? Кая барасың?)	Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкарь иү, раслау)		
1.	Коля							
2.	Оля							

Нәтиҗәләрне билгеләү	
Югары дәрәҗә 2,7 дән 3 кә кадәр	Бала сөйләмдә актив, үзлектән сорау бирә, яхшы аралаша.
Уртача дәрәҗә 2 дән 2,6 га кадәр	Сүз байлыгы бар, тәрбияче ярдәмендә аралаша.
Уртачадан түбән дәрәҗә 1 дән 2 гә кадәр	Аңлый, русча җавап бирә.

1.“Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану.
(Өйрәнгән темалар буенча биш – алты рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә кушыла)

1. ***Дидактик уен “Бу нәрсә?”***
   (Лексика: тычкан, бүре, төлке, керпе, тавык, әтәч, үрдәк, аю).
   Уен эчтәлеге: Тәрбияче рәсемнәргә күрсәтеп сорый:
- Бу нәрсә? (“бүре”...)
2. ***Дидактик уен “Портфельдә нәрсә бар?”***
   (Лексика: китап, дәфтәр, рәсем, мәктәп).
   Уен эчтәлеге: Тәрбияче портфельдән рәсемнәр яки предмет алып күрсәтә, исемен сорый:
   -Портфельдә нәрсә бар?- (“Дәфтәр бар”...)
3. ***Дидактик уен “Портфельдә нәрсә юк?”***
   Бала нәрсә юклыгын әйтергә тиеш. Уенны рәсемнәр кулланып та үткәрергә була.
4. ***Дидактик уен “Дөресен әйт”***
   (Лексика: чәк- чәк, өчпочмак, бәрәңге, аш, ботка, су).
   Уен эчтәлеге: Балага рәсемнәр бирелә. Бала рәсемнәрне атый.
   Югары балл (2.7-3) — 10-14 сүз.
   Уртача балл (2-2,6) – 7-9 сүз.
   Уртачадан түбән балл (1-2) – 1-6 сүз.

2. Ягымлы сүзләр куллану
(“Исәнме”, “Исәнмесез”, “Сау бул”, “Сау булыгыз”, “Рәхмәт”, “Зур рәхмәт”,
“Хәерле көн”,“Хәлләр ничек?”, “Әйбәт”)

Ситуатив күнегү:

Телефоннан сөйләшү.

Эш дәфтәрендәге 1 нче биремне кулланып була**.**

Югары балл (2,7-3) — бала сөйләмдә ягымлы сүзләрне урынлы куллана.

Уртача балл (2-2,6) – тәрбияче ярдәмендә җавап бирә.

Уртачадан түбән балл (1-2) – аңлый, сорауларга җавапны русча бирә.

3. Боерыкны бирә белү.

(Лексика: кил монда, утыр, сикер, ю, аша, эч, уйна, ки, сал, йөгер, бие, җырла, йокла).

Дидактик уен: "Командир"

Эш дәфтәрендәге 9 нчы биремне кулланып була**.**

Бер бала икенче балага боерык бирә. Мәсәлән:

-Коля, сикер! (Коля сикереп күрсәтә).

-Коля, син нишлисең?(Колядан сорый) – Мин сикерәм.

-Коля нишли? (Башка баладан сорый) – Коля сикерә.

Югары балл (2,7-3) — 11-13 сүз белән боерык бирә, син нишлисең, нишли сорауларын бирә белә.

Уртача балл (2-2,6) – бары боерык бирә, сорауларны куя алмый.

Уртачадан түбән балл (1-2) – 1-5 сүз белән боерык бирә, сорауларны русча әйтә.

4. Уен ситуацияләрендә үзлектән сорау бирә белү.

(Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Син кем? Бу кем? Бу нәрсә? Нишли? Кая барасың?)

1. Уен ситуацияләре:

а) "Кибет" (Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә?)

б) "Телефоннан сөйләшү" (Кая барасың? Син нишлисең?)

в) "Танышу" (Син кем? Бу кем? Бу нәрсә? Нишли?)

2. Сюжетлы-рольле уен "Кибет"

Балаларга рус телендә кибет уены үткәрү аңлатыла һәм өч төп сорауны куллана белүләре тикшерелә.Уен яшелчә, киемнәр, савыт-саба, өй җиһазлары, йорт кошлары, уенчык рәсемнәре кулланып үткәрелә.

(Лексика: Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә?).

2. Дидактик уен "Нинди?".

Тикшерүдә сорауларны аерым кулланып та үткәрергә була.

(Лексика: кызыл, сары, яшел, зәңгәр, ак, кара).

3. ***__Дидактик уен “Сана”.__***

Санау күнекмәләрен билгеләү (1- 10 кадәр).

__Югары балл (2,7-3)__ – сорауларны аңлап куллана**.**
__Уртача балл (2-2,6)__ – аңлый, тәрбияче ярдәме белән куллана**.**
__Уртачадан түбән (1-2)__ – русча җавап бирә.

5. Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкарь итү, раслау)

1. __Уен ситуациясе “Әйдәгез танышабыз”__

- Исәнмесез. Син кем? - (Мин Оля яки Коля).
- Мин кыз. Син кыз? - (Юк, мин малай).
- Сиңа ничә яшь?- (6 (7) яшь).

2. __Уен ситуациясе “Телефоннан сөйләшү”.(диалогны сан, сыйфат, күләм берәмлеге кертеп баетырга була)__

- Исәнме. Хәлләр ничек?
- Әйбәт.
- Нишлисең?
- Мин уйныйм. Син нишлисең?
- Мин ашыйм.
- Нәрсә?
- Алма ашыйм.
- Алма тәмле(ме)?
- Әйе, алма тәмле.
- Сау бул.

3. ***__Уен ситуациясе “Кая барасың?”__*** (*мәктәп, кафе, цирк һ.б.*)

- Исәнме! Хәлләр ничек?

- Әйбәт, рәхмәт.
- Кая барасың?
- Кафега барам.
- Кафеда нәрсә бар?
- (ашамлыклар атарга мөмкин)
- Саша нишли?
- Саша бәрәңге ашый.

4.***<u>Ситуатив күнегү.</u>***

а) Син нишлисең?

- Мин биим (утырам, сикерәм, ашыйм, эчәм, уйныйм, йөгерәм, җырлыйм, йоклыйм).

<u>Югары балл (2,7-3)</u> – бала сөйләмдә актив, үзлектән сорау бирә, яхшы аралаша.

<u>Уртача балл (2-2.6)</u> – сүз байлыгы бар, тәрбияче ярдәмендә аралаша.

<u>Уртачадан түбән (1-2)</u> – аңлый, русча җавап бирә.

2.6. Ата- аналар белән эш *(Кушымта №2)*

- Икенче кечкенәләр төркеменә яңа килгән татар милләтеннән булган балаларның ата – аналары белән анкета үткәрү.
- Ата – аналар җыелышында чыгышлар ясау.
- Консультацияләр үткәрү.
- Ачык ишекләр көне үткәрү.
- Балалар бакчасының сайтында информацияләрне яңартып тору.
- “Татарча сөйләшәбез” – “Говорим по – татарски” папкаларындагы информацияләрне яңартып тору.
- Индивидуаль консультацияләр бирү, әңгәмәләр үткәрү.
- Ата- аналарның, балаларның рәсемнәре күргәзмәсе үткәрү.

2.7. Педагогик коллектив белән эш *(Кушымта №3)*

- Педагоглар өчен татар теленә өйрәтү курслары үткәрү.
- Педагогик киңәшмәләрдә чыгышлар ясау.

- Консультацияләр бирү.
- Төркем тәрбиячеләре һәм белгечләр белән берлектә бәйгеләр үткәрү.
- Ачык ишекләр көнендә эшчәнлек күрсәтү.

2.8. Мәктәп белән бәйләнеш *(Кушымта №4)*

- Мәктәп һәм бакча балалары белән уртак бәйрәмнәр үткәрү.
- Ата- аналар җыелышларына гимназия һәм мәктәп укытучыларын чакыру.
- Үзара эшчәнлек һәм дәресләр карау.

III НЧЕ ОЕШТЫРУ БҮЛЕГЕ

3.1. Татар телен өйрәтүдә кулланыла торган чаралар

1. Эшчәнлек эшкәртмәләре, диагностик материаллар.
2. Тавышлы күрсәтмәлелек (һәр проект өчен аудиоязмалар, ани-мацион сюжетлар, мультфильмнар).
3. Картиналы һәм картиналы-дидактик күрсәтмәлелек (таратма һәм күрсәтмә рәсемнәр, җырлы-биюле уеннар, театр эшчәнлеге өчен атрибутлар).
4. Символик, график күрсәтмәлелек (пиктограммалар).
5. Күләмле күрсәтмәлелек (макетлар, муляжлар, уенчыклар).
6. Интерактив уеннар.
7. Эш дәфтәрләре.

Программалы - методик яктан тәэмин ителеш

Зарипова З.М., Кидрячева Р. Г. Балалар бакчасында рус телле балаларга татар теле өйрәтү программасы. «Идел-Пресс», 2013.

Кидрячева Р.Г. “Татарча сөйләшәбез”. 4-5 яшьлек балаларны татар теленә өйрәтү буенча методик ярдәмлек, «Хәтер», 2011.

Кидрячева Р.Г. “Татарча сөйләшәбез”. 5-6 яшьлек балаларны татар теленә өйрәтү буенча методик ярдәмлек, «Хәтер», 2012.
Кидрячева Р.Г. “Татарча сөйләшәбез”. 6-7 яшьлек балаларны татар теленә өйрәтү буенча методик ярдәмлек, «Татарстан китап нәшрияты», 2012.

Предметлы - үстерелешле әйләнә тирәлек

Эш дәфтәрләре

Кидрячева Р.Г. «Татарча сөйләшәбез». 4-5 яшьлек балалар өчен эш дәфтәре, «Хәтер», 2012.
Кидрячева Р.Г. «Татарча сөйләшәбез». 5-6 яшьлек балалар өчен эш дәфтәре, «Хәтер», 2012.
Кидрячева Р.Г. «Татарча сөйләшәбез». 6-7 яшьлек балалар өчен эш дәфтәре, “Татарстан китап нәшрияты», 2012.

Тавышлы күрсәтмәлелек

Кидрячева Р.Г.   “Минем өем” проеты буенча 4-5 яшьлек балалар өчен укыту-методик комплектына аудиоязмалар. “Аксу” компаниясе, 2012.
Кидрячева Р.Г.   “Уйный- уйный үсәбез” проекты буенча 5-6 яшьлек балалар өчен укыту-методик комплектына аудиоязмалар. “Аксу” компаниясе, 2012.
Кидрячева Р.Г.   “Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар”, проекты буенча 6-7 яшьлек балалар өчен укыту-методик комплектына аудиоязмалар. “Аксу” компаниясе, 2012.
Кидрячева Р.Г. “Минем өем” проекты буенча 4-5 яшьлек балалар өчен анимацион сюжетлар. “Аксу” компаниясе, 2012.
Кидрячева Р.Г. “Уйный- уйный үсәбез” проекты буенча 5-6 яшьлек балалар өчен анимацион сюжетлар. “Аксу” компаниясе, 2012.

Күрсәтмә, таратма материаллар,
театр эшчәнлеге өчен атрибутлар.

“Минем өем” проекты буенча 4-5 яшьлек балалар өчен

1.А4 форматында күрсәтмә рәсемнәр.	«Минем гаилә» Бабай, әби, әти, әни, малай, кыз.	Һәрберсе 1 данә
	Зур уенчыклар: курчак, куян, аю, туп, песи, эт, машина. Кечкенә уенчыклар: курчак, куян, аю, туп, песи, эт, машина.	Һәрберсе 1 данә
	«Ашамлыклар» Ипи, алма, чәй, сөт.	Һәрберсе 1 данә
	«Уенчыклар» Курчак, куян, аю, туп, песи, эт, машина. курчак, куян, аю, туп, песи, эт, машина – пычрак уенчыклар.	Һәрберсе 1 данә
	Сюжетлы рәсемнәр: «Куян өйгә керә, өйдә аю утыра». «Куян өйдән чыга, саубуллаша».	Һәрберсе 1 данә
	Рәсемнәр: 1 куян, 2 куян, 3 куян, 4 куян, 5 куян; 1 аю, 2 аю, 3 аю, 4 аю, 5 аю; 1 курчак, 2 курчак, 3 курчак, 4 курчак, 5 курчак; 1 туп, 2 туп, 3 туп, 4 туп, 5 туп; 1 машина, 2 машина, 3 машина, 4 машина, 5 машина; 1 песи, 2 песи, 3 песи, 4 песи, 5 песи; 1 эт, 2 эт, 3 эт, 4 эт, 5 эт.	Һәрберсе 1 данә
2.А3 форматын	Өй макеты	1 данә

да өй рәсеме.		
3. А 5 форматында таратма рәсемнәр.	«Минем гаилә» Бабай, әби, әти, әни, малай, кыз.	Һәрберсе 15 данә
	«Ашамлыклар» Ипи, алма, чәй, сөт.	Һәрберсе 15 данә
	«Уенчыклар» Курчак, куян, аю, туп, песи, эт, машина.	Һәрберсе 15 данә
4. Театр эшчәнлеге өчен атрибутлар.	Битлекләр: бабай, әби, әти, әни, малай, кыз, куян, аю, песи, эт.	Һәрберсе 15 данә
Бармак уеннары өчен атрибутлар	бабай, әби, әти, әни, малай, кыз, эт Акбай, песи Мияу, аю, куян.	Һәрберсе 15 данә

“Уйный-уйный үсәбез” проекты буенча 5-6 яшьлек балалар өчен

1. Күрсәтмә рәсемнәр.	«Минем гаилә» Малай, кыз рәсемнәр («Курчакны киендер» уены. Кыз, малай өчен киемнәр: күлмәк (кызларныкы, малайларныкы), футболка, шорты, чалбар, сарафан - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).	Һәрберсе 1 данә

	«Уенчыклар» Зур уенчыклар: курчак, туп, машина - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). Кечкенә уенчыклар: курчак, туп, машина - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).	Һәрберсе 1 данә
	«Ашамлыклар» Аш, ботка, чәк-чәк, конфет, сок.	Һәрберсе 1 данә
	«Савыт-саба» Зур рәсемнәр: кашык, тәлинкә, чынаяк - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). Кечкенә рәсемнәр: кашык, тәлинкә, чынаяк - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).	Һәрберсе 1 данә
	«Җиләк-җимешләр» Зур рәсемнәр: яшел алма, сары, кызыл, банан, апельсин, виноград, груша. Кечкенә рәсемнәр: яшел алма, сары, кызыл, банан, апельсин, виноград, груша.	Һәрберсе 1 данә
	«Яшелчәләр» Зур рәсемнәр: кишер, бәрәңге, суган, кыяр, кәбестә. Кечкенә рәсемнәр: кишер, бәрәңге, суган, кыяр, кәбестә.	Һәрберсе 1 данә
	«Киемнәр» Зур рәсемнәр: күлмәк (кызларныкы, малайларныкы), чалбар - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). Кечкенә рәсемнәр: күлмәк (кызларныкы, малайларныкы), чалбар - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).	Һәрберсе 1 данә
	«Өй җиһазлары» Зур рәсемнәр: карават, урындык, өстәл - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). Кечкенә рәсемнәр: карават, урындык, өстәл - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).	Һәрберсе 1 данә
	«Төсләр» Палитра: зәңгәр, кызыл, сары, яшел.	Һәрберсе 1 данә
	«Саннар»10)	Һәрберсе 1 данә

2. Таратма рәсемнәр.	«Минем гаилә» Малай, кыз рәсемнәре: («Курчакны киендер» уены. Кыз, малай өчен киемнәр: күлмәк (кызларныкы, малайларныкы), футболка, шорты, чалбар, сарафан - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).	Һәрберсе 15 данә
	«Уенчыклар» Зур уенчыклар: курчак, туп, машина - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). Кечкенә уенчыклар: курчак, туп, машина - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).	Һәрберсе 15 данә
	«Ашамлыклар» Аш, ботка, чәк-чәк, конфет, сок.	Һәрберсе 15 данә
	«Савыт-саба» Зур рәсемнәр: кашык, тәлинкә, чынаяк - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). Кечкенә рәсемнәр: кашык, тәлинкә, чынаяк - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).	Һәрберсе 15 данә
	«Җиләк-җимешләр» Зур рәсемнәр: яшел алма, сары, кызыл, банан, апельсин, виноград, груша. Кечкенә рәсемнәр: яшел алма, сары, кызыл, банан, апельсин, виноград, груша.	Һәрберсе 15 данә
	«Яшелчәләр» Зур рәсемнәр: кишер, бәрәңге, суган, кыяр, кәбестә. Кечкенә рәсемнәр: кишер, бәрәңге, суган, кыяр, кәбестә.	Һәрберсе 15 данә
	«Киемнәр» Зур рәсемнәр: күлмәк (кызларныкы, малайларныкы), чалбар - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). Кечкенә рәсемнәр: күлмәк (кызларныкы, малайларныкы), чалбар - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).	Һәрберсе 15 данә
	«Өй җиһазлары» Зур рәсемнәр: карават, урындык, өстәл - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә). Кечкенә рәсемнәр: кровать, стул, стол - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).	Һәрберсе 15 данә

3.Буяу өчен график рәсемнәр	1 аю, 2 куян, 2 машина, 2 курчак, 3 бәрәңге, 4 кәбестә, 4 курчак, 5 песи, 6 алма, 6 кыяр, 7 туп, 7 бәрәңге, 8 кишер, 9 суган, 10 эт.	Һәрберсе 15 данә
4.Театр эшчәнлеге өчен атрибутла р.	Битлекләр: кишер, суган, кыяр, бәрәңге, кәбестә, алма.	Һәрберсе 15 данә
5. Театр эшчәнлеге өчен атрибут лар.	1.Өстәл театры өчен атрибутлар (конус формасында): «Өч аю»: әти аю, әни аю, бала аю. 2. Өстәл театры өчен атрибутлар (конус формасында): «Кем нәрсә ярата»: песи, эт, аю, куян, кәҗә, әтәч. өстәл (зур, уртача зурлыкта, кечкенә); урындык (зур, уртача зурлыкта, кечкенә); карават (зур, уртача зурлыкта, кечкенә).	Һәрберсе 1 данә Һәрберсе 1 данә

“Без инде хәзер зурлар-мәктәпкә илтә юллар” проекты буенча 6-7 яшьлек балалар өчен

1.А 4 форматын а күрсәтмә рәсемнәр.	Үрдәк, бүре, әтәч, тавык, зур тычкан, кечкенә тычкан, китап, альбом, клей, линейка, ручка, карандаш, пенал, дәфтәр, кофе, пицца, бәрәңге фри, өчпочмак.	Һәрберсе 1 данә
	Шарлар - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).	Һәрберсе 1 данә
	Сюжетлы рәсемнәр: куян чана шуа, аю чана шуа, бүре чана шуа, төлке чана шуа, үрдәк чана шуа, тавык чана шуа, тычкан чана шуа, төлке бии, керпе йоклый, бүре йөгерә, төлке утыра, керпе уйный, аю йоклый, песи сөт эчә, эт ашый, төлке йөгерә, куян	Һәрберсе 1 данә

	сикерә, тычкан ашый, әтәч җырлый, кыз кул юа, малай китап укый, кыз китап укый, төлке китап укый, куян китап укый, әни кул юа, әти йоклый, малай утыра, кыз бит юа, әби утыра, бабй йоклый.	
2. А 5 форматында таратма рәсемнәр.	Үрдәк, бүре, әтәч, тавык, зур тычкан, кечкенә тычкан, китап, альбом, клей, линейка, ручка, карандаш, пенал, дәфтәр, кофе, пицца, бәрәңге фри, өчпочмак.	Һәрберсе 15 данә
	Шарлар - (зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдә).	Һәрберсе 15 данә
	Сюжетлы рәсемнәр: куян чана шуа, аю чана шуа, бүре чана шуа, төлке чана шуа, үрдәк чана шуа, тавык чана шуа, тычкан чана шуа, төлке бии, керпе йоклый, бүре йөгерә, төлке утыра, керпе уйный, аю йоклый, песи сөт эчә, эт ашый, төлке йөгерә, куян сикерә, тычкан ашый, әтәч җырлый, кыз кул юа, малай китап укый, кыз китап укый, төлке китап укый, куян китап укый, әни кул юа, әти йоклый, малай утыра, кыз бит юа, әби утыра, бабай йоклый.	Һәрберсе 15 данә
8x10 форматында пиктограммалар	Бии, йоклый, утыра, ашый, эчә, уйный, сикерә, йөгерә, укый, рәсем ясый, җырлый, чана шуа, мин, кыз, малай, әби, бабай.	Һәрберсе 15 данә
15x20 форматында пиктограммалар	Бии, йоклый, утыра, ашый, эчә, уйный, сикерә, йөгерә, укый, рәсем ясый, җырлый, чана шуа, мин, кыз, малай, әби, бабай, куян, төлке, песи, эт, аю, әтәч, тавык, үрдәк, керпе, тычкан.	Һәрберсе 1 данә

3.2. Материаль - техник яктан тәэмин ителеш

Татар теле кабинеты	Белем бирү эшчәнлеге, индивидуаль, коррекцион эш, ата-аналар, педагоглар өчен консультацияләр, ачык эшчәнлекләр .	Зурлар һәм балалар өчен өстәлләр, урындыклар, компьютер, принтер, интерактив такта, ноутбук, магнитофон, уенчыклар, дидактик, интерактив уеннар, балалар әдәбияты, тематик папкалар, альбомнар, укыту -методик комплект (демонстрацион, таратма материал, аудио, видео дисклар, маскалар, театрларның төрле төрләре),ТР һәм РФ символикасы.

Циклограмма работы на неделю воспитателя (по обучению детей татарскому языку)
Балаларга татар теле өйрәтүче тәрбияченең эш көне бүленеше
Зиганшиной Э. И.

Дни недели	Время	Деятельность	Виды деятельности
